**КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**

**Габдрахманова Ф.Х.**

# ЧАГЫШТЫРМА ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ СИСТЕМАСЫНДА ТӘРҖЕМӘ

**КАЗАН**

**2016**

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

ЛЕВ ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ
МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ҺӘМ
МӘДӘНИЯТЕ БҮЛЕГЕ

**ГОМУМИ ҺӘМ ТӨРКИ ТЕЛ БЕЛЕМЕ КАФЕДРАСЫ**

# ЧАГЫШТЫРМА ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ СИСТЕМАСЫНДА ТӘРҖЕМӘ

**КАЗАН**

**2016**

УДК 373.167.1

ББК 81.2 (2 Рос=Тат)

КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Укыту-методик советы
(22 март, 2016 ел, 8 нче номерлы беркетмә)

гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы
(9 март, 2016 ел, 8 нче номерлы беркетмә)
карары белән басыла

Т ө з ү ч е

**Ф.Х.Габдрахманова**, филология фәннәре кандидаты, доцент

Ф ә н н и м ө х ә р р и р

**Р.Р.Җамалетдинов**, филология фәннәре докторы, профессор

Рецензентлар

**Мөгътәсимова Г.Р.**, филол. фән. канд., доцент (КФУ)

**Хөснетдинов Р.М.**, филол. фән. канд., доцент (КМТТУ)

**Габдрахманова Ф.Х.**

**Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә.** Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казан: КФУ, 2016. – 93 б.

Югары уку йортлары өчен төзелгән әлеге укыту кулланмасы тәрҗемәчелек белгечлеген үзләштерүче студентларга, магистрстрант һәм аспирантларга, укытучыларга, тел һәм әдәбият белән кызыксынучы киң катлам даирәгә тәкъдим ителә.

## ЭЧТӘЛЕК


**Кереш** ................................................................................... 4

**1 нче тема.** “Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсына кереш ................................................................... 6

**2 нче тема.** Әдәбиятның үсешендә тәрҗемәнең роле ............... 11

**3 нче тема.** Төрле халыкларның татар теленә тәрҗемә ителгән әдәбият үрнәкләре ........................................................ 19

**4 нче тема.** Татар теленнән рус теленә әдәби тәрҗемә итү эшчәнлеге ............................................................ 28

**5 нче тема** Рус әдәбияты үрнәкләре татар телендә .................. 37

**6 нчы тема.** Татар телендә Лев Толстой әсәрләре ..................... 45

**7 нче тема.** Татар телендәге тәрҗемәләрдә Көнбатыш әдәбияты ........................................................................... 50

**8 нче тема.** Тугандаш халыклар әдәбияты әсәрләренең татар теленә тәрҗемә ителеше .................................................. 63

**9 нчы тема.** Татар әдәбияты әсәрләренең төрки халыклар телләренә тәрҗемәсе ........................................................... 71

Имтихан өчен якынча сораулык ................................................. 75

Реферат темалары ....................................................................... 76

“Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсы буенча тест ................................................................................. 78

Курсны өйрәтүгә карата методик күрсәтмәләр ........................ 81

Тәрҗемә белеме терминнары сүзлеге (глоссарий) ............ 84

Чыганаклар .......................................................................... 86

Төп әдәбият ................................................................................. 89

Өстәмә әдәбият ............................................................................ 90

Интернет ресурслар ..................................................................... 93

# КЕРЕШ

“Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсы 032700.62 “Гамәли филология: мәдәниятара багланышлар һәм тәрҗемә” белгечлеге буенча өйрәнелә торган лингвистик фәннәр арасында үзенчәлекле урын алып тора. Ул студентларның уку барышында тәрҗемә теориясе, шулай ук әдәбият белеменнән теоретик һәм гамәли дәресләрдә тупланган белем-күнекмәләренә таянып оештырыла.

Әлеге кулланмада төрле халык әдәбияты әсәрләренең татарча чыккан тәрҗемәләре әдәбиятыбызга алып килгән яңа темалары, идеяләре, аны жанр ягыннан баетуы, әдәби тәрҗемәләрнең шул чор рухын чагылдыруы, нинди жанрларга, темаларга ихтыяҗ зур булганлыгы, актив тәрҗемәчеләр, тәрҗемә ителгән әсәрләрнең теле һ.б. турында теоретик материал бирелә. Алынган мәгълүматларны ныгыту, тирәнәйтү һәм киңәйтү өчен төрле халыклар әдәбиятыннан татар теленә һәм татар әдәбияты үрнәкләренең башка телләргә тәрҗемәләре буенча биремнәр тәкъдим ителә. Әлеге биремнәр фразеологизмнарны, реалияләрне тәрҗемә итүгә, тәрҗемәләрдә милли колоритны бирүгә, татар әдәбияты

белән башка милләт халыклары әдәбияты арасындагы уртаклык һәм аерымлыкларны ачыклауга нигезләнә.

“Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсыннан укыту кулланмасы татар филологиясе бүлегендә белем алучы студентлар өчен төзелде. Ярдәмлек теоретик материалны, гамәли дәресләрдә анализлау өчен тәкъдим ителә торган тел материалларын, реферат темаларын, әдәбият исемлеген, имтиханга әзерләнү өчен якынча сораулыкны, укытучы һәм студент өчен методик киңәшләрне үз эченә ала. Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, гамәли әзерлекне нәтиҗәлерәк итү максатыннан тест та китерелә.

## 1 НЧЕ ТЕМА. “ЧАГЫШТЫРМА ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ СИСТЕМАСЫНДА ТӘРҖЕМӘ” КУРСЫНА КЕРЕШ

Мәгълүм ки, һәрбер милли мәдәният, һәрбер милли әдәбият башка халыкларның сәнгате белән тыгыз мөнәсәбәттә яши, үзара бер-береңнән өйрәнү, тәҗрибә алмашу, иң яхшы сыйфатларны үзендә булдырырга омтылу – рухи тормыш үсеше өчен мөһим шарт. Г.Ибраһимов әлеге омтылышны түбәндәгечә характерлый: "*Тарихи гомумиядән бөтенләй хәбәрсез калып, фәкать татар тарихы белән генә танышу никадәрле берьяклылык бирсә, гомуми әдәбият тарихының башлыча дәвер вә агымнарыннан хәбәрсезлек тә шундый ук берьяклылык тудырачак*". Нәтиҗәдә, милли әдәбиятларның үсеш чорына (татар әдәбиятында 19 йөзнең ахыры – 20 йөзнең башы) тәрҗемәнең активлашуы хас була. Татар әдәбиятында, беренче чиратта, халыкның тормышына, милли аңга, фикерләүгә ятышлы әсәрләр – матди нигез уртаклыгы булган рус әдәбияты һәм рухи өлкәдә нәтиҗәле охшашлыклар яшәгән төрек әдәбиятыннан тәрҗемәләр көчәя. Дөрес, бу этапта гарәп-фарсы әдәбиятыннан өлге алып язылган, яки татарчалаштырылган әсәрләр дә юк түгел. Әмма, гомумән алганда, тәрҗемә өлкәсендә төрек, бигрәк тә рус һәм алар аша Көнбатыш Европа

әдәбиятыннан үрнәкләр хакимлек итәләр. Моның сәбәбе: заман куйган проблеманы төрле яклап яктырткан, чынбарлыкның үзеннән чыга торган конфликтларны чагылдырырга алынган әсәрләр бу әдәбиятларда инде җитди үсү процессы кичергән булуы.

Тәрҗемә төрләре арасында иң катлаулы һәм авыр төрләрнең берсе булган **әдәби тәрҗемә** ул – бер телдә язылган әсәрне, аның стилистик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап калырга тырышып, икенче телгә күчерү. Оригиналь иҗаттан аермалы буларак, әдәби тәрҗемәгә оригиналга бәйлелек хас. Әдәби тәрҗемә – оригиналь әсәргә карата икенчел күренеш, ул иркле, төгәл һәм тәңгәл булырга мөмкин.

Әдәби тәрҗемәнең **максаты** – теге яки бу милләтнең рухи казанышы, хәзинәсе булган матур әдәбият әсәрен башка халыкларга җиткерү, әдәби багланышларны ныгыту.

**Бурычы** – белем, мәгълүмат бирү, матурлык хисе тәрбияләү. Теләсә нинди матур әдәбият әсәре тәрҗемә ителә алмый.

Төп **предметы** – әдәби әсәр.

Тәрҗемә әсәргә яңа форма кидертелә. Әгәр бу форма үзенең эшләнеше, дөреслеге, төгәллеге, матурлыгы белән элекке формасыннан түбән торса, икенче төрле итеп

әйткәндә, тәрҗемәсенең теле оригиналының теленнән начаррак, зәгыйфьрәк булса, әсәрнең эчтәлегенә, идеясенә, һичшиксез, зыян килә. Димәк, әдәби әсәрне мәгънәсе ягыннан гына түгел, ә эмоциональ яктан, интонация ягыннан, колорит ягыннан да дөрес тәрҗемә итү кирәк.

Тәрҗемә ул – чыганак телдән тәрҗемә теленә җиткерү өчен алынган билгеле бер мәгълүматны үз эченә алган интеллектуаль эшчәнлек. Тәрҗемә эшен ике телне дә яхшы белгән тәрҗемәче башкара. Тәрҗемәчедән, иң беренче чиратта, интеллект, зәвык сорала. Тәрҗемәченең әсәрнең асылын, эчтәлеген, идеясен аңлавы, тәрҗемә берәмлекләренә (сүз, сүзтезмә, җөмлә) структур-семантик эквивалентлар таба белүе әһәмиятле.

Әдәби тәрҗемәчегә куелган **таләпләр:**

1) тәрҗемәдә оригиналның мәгънәсе, эчтәлеге тулы бирелү;

2) төп нөсхәнең форма үзенчәлекләре, автор стиле, сәнгать-милли үзенчәлеге тәрҗемәдә мөмкин булганча тулы гәүдәләнү;

3) сайлап алу, эзләү, иҗат иреге. Шулай да тәрҗемәче иҗат ирегеннән дөрес файдалана белергә тиеш, чама хисен аңларга, сак килергә тиеш. Тәрҗемәче, үзе теләгәнчә, текстны үзгәртеп, үзирекле тәрҗемә белән мавыгып,

авторга хыянәт итә алмый. Дөрес, тәрҗемә тарихында авторны төзәтү, әсәрне шомарту күренешләре дә күзәтелә.

**Әдәби тәрҗемәнең дүрт принцибы**

Хәзерге әдәби тәрҗемә фәнендә түбәндәге принциплар аерып карала: эчтәлек берлеге принцибы; стилистик берлек принцибы; иҗадилык принцибы, эстетик тәэсир итү.

**1)** Тәрҗемәнең төп принципларыннан берсе һәм иң әһәмиятлесе – оригиналның мәгънәсе, эчтәлек берлеге.

**2)** Тәрҗемәдә төп нөсхәнең форма үзенчәлекләре, автор стиле, сәнгать-милли үзенчәлеге мөмкин булганча тулы гәүдәләнергә тиеш.

**3)** Сайлап алу, эзләү тагын бер әһәмиятле принципка килеп тоташа. Иҗадилык принцибы – матур әдәбият тәрҗемәсендә, бигрәк тә поэтик тәрҗемәдә әһәмиятле принцип.

**4**) Һәр әдәби тәрҗемә әсәре – һичшиксез, тәрҗемәченең интеллектуаль һәм иҗади хезмәт нәтиҗәсе. Әдәби тәрҗемә сыйфатын бәяләүнең төп критерие булып тәрҗемәнең эстетик тәэсир итүе буенча оригиналга туры килүе, ягъни адекват булуы тора.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

*1. К.Миңлебаевның "Тәрҗемә – сәнгать ул!" мәкаләсен укып фикер алышыгыз.*

**2.** *Аварчадан (Дагыстан) Р.Корбан тәрҗемә иткән Мөхәммәт Әхмәтов шигырьләрен укыгыз, анализ ясагыз. Татар әдәбиятында аңа аваздаш шигырьләр бармы? Шигырь бербөтен булып укыламы?*

Йә төрмәгә тыга, йә бөлдерә –
Рәхимсез чор безгә бирә җәза.
Бәндә, мескен, белми ни кылырга,
Акрын гына акылыннан яза.
Таладылар ярты илнең малын,
Җимерделәр яши торган йортын.
Ә мазарда һәммәбез дә тигез.
Кайчан гына шуны аңларбыз соң?!

***

Илаһи Сүз түгел, буш сүзләрдән
Тулган чакта дала, калалар,
Күселәр дә арысланны җиңә,
Тәсбихлар да өзелеп тарала.
Шигырь – түгел шайтан вәсвәсәсе,
Чорлар уйлап тапкан уйдырма.
Ул намазга басып укыр өчен
Илаһиның Сүзен сыйдырган!

## 2 НЧЕ ТЕМА. ӘДӘБИЯТНЫҢ ҮСЕШЕНДӘ ТӘРҖЕМӘНЕҢ РОЛЕ

Тормыш куйган идеяләрне, проблемаларны сәнгатьтә яктырту һәм халыкка җиткерү өчен татар язучылары әдәбиятның бөтен чараларын да файдаланалар. Бу җәһәттән, "эзләнүләр" башка халыкларның әдәби үрнәкләренә мөрәҗәгать итү юлы белән дә башкарыла. XX йөз башында тәрҗемә әсәрләрнең иң зур күпчелеге нәкъ менә 1909-1911 елларга туры килүе моны тагын бер кат раслый.

Әлбәттә, тәрҗемәләр милли әдәбиятта мәгълүм бер эзләнүләргә, татар язучысының иҗаттагы борчуларына җавап биргәндә генә игътибарга лаек – аларның төп функциясе дә шунда. Г.Ибраһимов тәрҗемәнең "*татар халкының психологиясенә вә фикеренә туры килерлек ярашлы, аларның бер ярасына шифа бирерлек вә бер ихтыяҗларын капларлык бер әсәр*" булырга тиешлеген ассызыклап узган. Шул максаттан чыгып, татар әдипләре тәрҗемә иткәндә үзләреннән еш кына өстәмәләр кертүне дә рөхсәт итәләр. Татарчалаштырылган әсәрләр аркылы заманның актуаль проблемаларына шәхси мөнәсәбәтләрен белдерәләр, тормыш куйган кайбер мәсьәләләрне хәл итү бурычын да башкаралар. Төрек теленнән тәрҗемә ителгән

"Мәхәббәт корбаны" романында (тәрҗемә итүче Нурулла Әл-Камали, Казан, 1909) шундый "өстәмә иҗатны" күрәбез: "*Әнә аларның угылы Фәрид, Габдулла мөгаллимнең кызын алып бирегез дип, никадәр ялынды вә аталары илә тартышты, ата-анасы исә, безгә русча укый-яза белә торган кыз кирәкми дип алмадылар. Башка бер садә генә кешенең кызын алып бирделәр, ә кызлары русча укый-яза белү түгел, татарча да укый-яза белми имеш*". Күренә ки, әлеге өземтә һич кенә дә төрек әдәбиятына хас түгел. Бу, һичшиксез, тәрҗемәче тарафыннан өстәлгән җөмлә.

Татарчалаштырылган әсәрләрнең диапазоны киңәюен шул факт та раслап тора: тәрҗемәләр арасында Твен, Гамсун, Дойль, Дефо, Бичер-Стоу, Сальгари, Гульярдо, һ.б. фамилияләрне очратабыз.

Рус язучыларын өйрәнү, әсәрләрен тәрҗемә итү, ияреп язу XIX гасырда ук башланган булса да, 1905 елдан соң аеруча колач ала. Татар әдипләре А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, Л.Н.Толстой, А.И.Куприн, А.П.Чехов, И.С.Тургенев һ.б. әсәрләренә мөрәҗәгать итәләр.

Тәрҗемәләрнең татар әдәбиятында роле кискен көчәюен түбәндәге дәлил дә күрсәтеп тора.

1908 елны "Әлислах" (№41) газетасында мондый белдерү басыла: *"Русча, гарәпчә, төрекчә телләрдә язылган файдалы китапларны татарчага тәрҗемә итәр өчен, яшьләр үзара бер кружок ясап, тәкъдим өчен уставын бу көннәрдә губернаторга бирмәкче булалар".* Шуннан соңгы номерларда китап басучыларга мөрәҗәгать урнаштырыла башлый:

"*Көтепханәләр дикъкатенә:*

*Русча, гарәпчә, төрекчә китапларны тәрҗемә иттереп нәшер итүчеләр: әгәр китапларның дөрес гыйбарәле вә гүзәл рәвештә чыгуын теләсәләр, безнең тәрҗемәчеләргә мөрәҗәгать итсеннәр".*

Тәрҗемәнең бер рәвешле профессиональ югарылыкка куелуы сайлап алынган әсәрләрнең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә. Й.Нигъмәтуллина күрсәтүенчә, түгәрәк әгъзалары, беренче чиратта, рус язучыларының тирән социаль эчтәлеккә ия һәм алар фикеренчә, татар җәмгыяте өчен аеруча актуаль булган әсәрләрен тәрҗемә итәргә карар кылалар.

Реакция елы тудырган идеологик кризистан, караңгы, куе буяуларга манчылган тасвир-вакыйгалардан гыйбарәт булган тәрҗемә әсәрләрнең басылуы – татар язучыларының иҗат кыйблаларын ачыклауда, заман

куйган четерекле мәсьәләләрне чишәргә тырышуында бер этәргеч була.

Ф.Әмирхан күренекле рус язучысы Л.Андреевның "Рассказ о семи повешенных" повесте тәрҗемәсендә ("Асылган җиде кешеләр хикәясе": Казан, 1909) язган сүз башында шундый аңлатма бирә: "*...әдәбиятны кәеф- сафа өчен моталәга итүчеләр (укучылар) бу хикәядән ул нәрсәләрне көтмәсеннәр"*, – ди, һәм мондый типтагы әсәрләрне *"безнең хәзерге тормышыбызның нифаксыз (алдаусыз) көзгеләре"*, – дип атый.

Шушы чорның рухын, эчтәлеген тәрҗемәләрнең характерыннан да тоярга мөмкин. Зыя Насрый Көнбатыш әдәбиятыннан (авторы күрсәтелмәгән) бер үрнәк итеп "Поездда гарип бер угрылык" (1908) хикәясен татар укучысына тәкьдим итә. Солтан Рахманколый В.Гюгоның "93-й год" романын кыскартылган вариантта (башлыча бер өлеше алынып, хикәя рәвешендә эшләнгән) "Туганга каршы туган, яхуд вөҗдан газабы" (1910) исеме белән тәрҗемә итә. Атамасыннан ук аңлашылганча, тәрҗемәче төп игътибарны "бурыч" белән "йөрәк" бәрелешенә, әхлакый эзләнүләрнең катлаулы эволюциясенә юнәлтә, әсәрдә шәхеснең еш кына аянычлы нәтиҗәләргә китергән үз эчендәге хисләр көрәше алгы планга чыга.

Тәрҗемәләр татар әдипләре өчен заман куйган күп санлы сорауларга җавап эзләү рәвешендә генә түгел, ә чор рухын чагылдыру юнәлешендә мөһим тәҗрибә мәктәбе дә булалар. Башка халыклар әдәби үрнәкләренә ияреп язылган әсәрләрнең барлыкка килүе дә шул максаттан туган ихтыяҗ.

Мисал өчен, Зариф Бәшири 1911 елда Антон Чеховка ияреп, "Фаэтончы" хикәясен иҗат итә. "Фаэтончы" (извозчик) Сәлимҗан агай олы хәсрәтеннән югалып бетеп, чатта пассажирлар көтә: аның угылы Батыргәрәй үлгән икән һәм ул бу кайгысыннан тәмам бөкрәйгән, өстенә яуган кар аны боз баганасы кебек күрсәтә. Менә ул хәсрәтен пассажиры – офицер белән уртаклашмакчы була әмма тегесе кызып: "Бар син Батырыңның каберен сакларга!" – дип сикереп төшеп кала. Бераздан карт юлдашлары студентларга да кайгысын аңлатырга азаплана, ләкин ваемсыз яшьләр аннан көләләр генә. Сәлимҗан агайның җаны телгәләнә: "Ярабби! Инсаннар кайчан шулай бер-берсенә йомшаклык белән якынлашырлар вә шәфкать белән сырынырлар икән?" Кешеләрнең үз хәлен тыңларга теләмәвеннән гаҗиз булган карт чарасыздан бар кайгысын үзенең кара юргасына сөйли. Аның газаплануы , хәсрәтеннән нишләргә белмәве моң булып ташып чыга.

Хикәянең башыннан ахырына кадәр бер үк мотив: кайгы-хәсрәт, гаҗизлек, өметсезлек.

1911 елда Һади Килдебәков Кнут Гамсунның "Ачлык" романын тәрҗемә итә. Җанөшеткеч караңгы төсләр белән сугарылган бу әсәр татар демократик яшьләренә, мохтаҗлыкта яшәгән ярымач шәкертләргә аңлаешлы була.

Шундый соң чиккә барып җиткән, әмма кешелеген югалтмаган геройның (никадәр мохтаҗлыкта яшәсә дә ул теләнүдән, мескенләнүдән баш тарта) "*безнең өчен зур бер гыйбрәт булырлыгына"* басым ясап, Һ.Килдебәков, романны укып "*мөхәррирләребез үз әсәрләребез вә үз укучыларыбызга да әйләнеп карасыннар иде*", ди.

Г.Тукай "Казанга кайтыш" (1912) очеркында болай искә ала: *"...бер бүлмәгә күчтем. Апалы-сеңелле ике марҗа – хозяйкаларым. Мещанкалар, кабахәтләр, мещанкалар.*

*Максим Горькийны укыганда – шуларга нәфрәтем, Кнут Гамсунны укыганда – шуларга ләгънәтем”* (Тукай, 1986, V; 42).

Караңгы, тетрәндерерлек аянычлы мотивлар мавыктыргыч, маҗаралы әсәрләргә дә үтеп керәләр, һәр хәлдә, авантюр сюжетка табынган әдипләр дә, тәрҗемә иткәндә шул рухтагы әсәрләргә мөрәҗәгать итәләр. М.Ибраһими һәм Г.Барый тарафыннан татар теленә

күчерелгән "Миллионнар табу" (авторы күрсәтелмәгән, 1909) әсәре җәмгыятьтә кешенең роле, дәрәҗәсе акчага мөнәсәбәттә каралу вакыйгаларын сөйли. Миллионнарга ия булу омтылышы хәтта иң намуслы, кешелекле геройларның да шәхес буларак үзгәрүенә, фаҗигале хәлләргә таруына сәбәп була, шуңа бәйләнештә әсәрдә шәхеснең деградация процессы бара, вакыйгалар аянычлы, трагик төгәлләнә.

Тәрҗемәләрнең татар әдәбиятындагы роле янә шунда да: үткен социаль проблемалы әсәргә мөрәҗәгать итү критик реализм принципларын үзләштерүдә мөһим бер чара. Әдипләрнең И.С.Тургенев, А.П.Чехов, А.И.Куприн, кебек рус әдәбияты классикларына мөрәҗәгать итүләре милли әдәбиятта ул иҗат методын кабул итәргә җирлек әзерләнгәннәрен раслый. Шул рәвешле, башка халыкларның әдәби үрнәкләре белән танышу татар язучыларына иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең асылына төшенергә булыша, алар яктылыгында үз халкының тарихын аңлау, үсү перспективаларын билгеләү өчен җирлек әзерли.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1**. К.Миңлебаевның "Язучы һәм тәрҗемәче" мәкаләсен укып фикер алышыгыз.*

**2.** *Башкорт шагыйре Шәрәф Бикколның шигырьләрен укыгыз (Х.Әюп тәрҗемәсе), анализ ясагыз. Шигырь бербөтен булып укыламы? Татар әдәбиятында учак нәрсә белән символлаша? Ут символы кергән әсәрләрне атагыз.*

УЧАК ҺӘМ КОЧАК

Бу җирдә
җәннәт дигәнең
ярын. ачкан кочак икән.
Дөнья үзе –
мәңгелек ут,
сүнми янган учак икән...
Ут дөрләвен туктатмауда
һәркемнең бар
үз өлеше:
учагына кочак-кочак
чытыр өстәп тора кеше.
Менә шулай
үлчәп тормый
бәхет өчен сарыф көчен,
бәндә җанын фида кыла
учак өчен,
кочак өчен!

***

Толларга да шатлык килми тормый:
толлар да бит гөнаһ җан түгел;
дөньясы да яктылыкка чумган, –
нур өләшү аңа җәл түгел.
Бер мизгелгә генә шыр бушанып,
бизеп беткән кайгы йөгеннән,
бик көттереп килгән кунак сыман,
куна шатлык толлар йөзенә.
Зәңгәр чәчкә түгел,
бу мәлләрдә
алар,
гүя, –
сары көнбагыш:
йөзләрендә шатлык биесә дә,
күзкәйләре тулы моң-сагыш...

## 3 НЧЕ ТЕМА. ТӨРЛЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ ҮРНӘКЛӘРЕ

Татар теленә беренче мәртәбә кайчан һәм кайсы халык әдәбияты әсәре тәрҗемә ителгән дигән сорауга җавап бирүе кыен. Бик борынгы кульязмаларның күбесе безнең

көннәргә хәтле сакланмаган. Ә инде урта гасырлардан килгән кулъязмаларга караганда, татар халкы көнчыгышның классик әдәбияты һәм фольклоры белән шактый киң таныш булган. Шул чор татар әдәбияты истәлекләре гарәп, фарсы, үзбәк, һинд, әзербәйҗан, төрек, грек, еврей әдәбиятларыннан алынган тәрҗемәләргә, шул халыклар фольклорыннан кергән сюжетларга, образларга шактый бай.

Татар телендә типография ысулы белән китап басу эше оештырылгач, туган телебезгә башка халыклар әдәбияты әсәрләрен тәрҗемә итү тагын да киңәя төшә. Көнчыгыш әдәбияты әсәрләреннән тыш Россия һәм Европа илләре халыкларының әсәрләре дә тәрҗемә ителә, басыла башлый.

Революциягә хәтле үк инде татар телендә Көнчыгыш халыклары әдәбиятыннан тыш, француз, немец, инглиз, дания, голланд, испан, итальян, поляк әдәбияты үрнәкләре дә басыла.

Татар теленә киң тәрҗемә ителүе ягыннан бу чорда беренче урынга рус әдәбияты чыга. Рус әдәбиятыннан Л.Н. Толстой, И.А. Крылов, А.П. Чехов, И.С. Тургенев, А.И. Куприн, Н.В. Гоголь, М.Ю. Лермонтов, А.С. Пушкин һ.б. күп кенә рус язучыларының әсәрләре басылып килә. Россия халыкларыннан осетин, украин, черкас, уйгур,

төрекмән әдәбияты һәм фольклоры әсәрләре татар матбугатында күренә башлый. Тәрҗемә аша киң укучылар массасын башка халыкларның әдәбиятлары белән таныштыру өчен зур мөмкинлекләр Бөек Октябрь революциясеннән соң гына туа.

Әгәр революциягә хәтле татар теленә 15-20ләп милләтнең матур әдәбият әсәрләре тәрҗемә ителсә, революциядән соң (1963 елның башына кадәр) татар телендә 114 чит әдәбият әсәрләрен укырга мөмкин була.

Татар теленә иң күп тәрҗемә ителгән әдәбият – бөек гуманизм, азатлык идеяләре белән сугарылган, дөньяда иң алдынгы классик рус әдәбияты.

1917 елдан алып 1963 елның башына хәтле рус әдәбиятыннан 553 язучының әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән. Шуның өстенә, әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителмәгән 29 рус язучысының тормыш һәм иҗат юлы турында татар матбугатында әдәби тәнкыйть мәкаләләре басылган. Әсәрләре татар теленә күп тәрҗемә ителгән язучылар арасында иң беренче урында А.М.Горький тора. Аның романнары, хикәяләре татар телендә 10 тапкыр сайланма әсәрләр җыентыгы (2се 6 томлык) һәм 54 тапкыр аерым китап булып, барлыгы 400 мең данә белән басылган. Шуның өстенә А.М.Горький

әсәрләре журналларда, җыентыкларда да күп мәртәбәләр нәшер ителгән.

А.С.Пушкин әсәрләре дә татар телендә күп таралган. Аның сайланма әсәрләре 6 тапкыр басылган. Шигырьләре, романнары, әкиятләре аерым китап булып 47 тапкыр, барлыгы 408 мең тираж белән чыккан.

А.М.Горький, А.С.Пушкиннан кала татар телендә Л.Н.Толстой (320 мең тираж белән 34 тапкыр), А.П.Чехов(165мең тираж белән 21 тапкыр), И.С.Тургенев (120 мең тираж белән 15 тапкыр), М.Ю.Лермонтов (100мең тираж белән 14 тапкыр ). С.Маршак, А.Толстой, А.Фадеев, Н.Гоголь, Н.Некрасов, В.Маяковский, Д.Мамин-Себеряк, Кассиль, А.Гайдар, Б.Житков һ.б. әсәрләре күп мәртәбәләр басылып чыкканнар.

XX гасыр башыннан шул гасырның урталарына кадәр рус әдәбиятыннан тәрҗемә ителеп, татар телендә басылган китаплар саны 800 дән арта, гомуми тиражы 7 миллион чамасы хисаплана.

Татар телендә рус әдәбияты тарихын һәм аерым язучыларның, сәнгать эшлеклеләренең тормыш һәм иҗатын чагылдырган йөзләрчә әдәби тәнкыйть мәкаләләре басыла. Матбугатта рус халкының 24 художнигы,

композиторы, артисты һ.б. сәнгать эшлеклеләренең иҗаты турында белешмәләр китерелгән.

Шушы башкарылган зур эшләр нәтиҗәсендә хәзер татар халкы рус әдәбиятының бөек классикларын гына түгел, башка йөзләгән язучыларның әсәрләрен дә үз ана телендә укый ала. Рус әдәбиятын туган телебезгә киң тәрҗемә итү әдәбиятыбызны бермә-бер баетты, үстерде.

Татар телендә басылу ягыннан рус әдәбиятыннан соң икенче урында тугандаш башкорт әдәбияты тора. Татар матбугатында 72 башкорт язучысының әсәрләре басылган. Журналларда, әдәби җыентыкларда басылган әсәрләрдән тыш башкорт язучыларының әсәрләре 65 китап булып, 300 мең тираж белән басылып чыккан.

Революциягә хәтле татар теленә, Т.Г.Шевченко әсәрләреннән кала, украин әдәбиятыннан тәрҗемәләр бөтенләй булмаган. Революциядән соң татар теленә 61 украин язучысының әсәрләре тәрҗемә ителә.

Тугандаш чуваш әдәбияты да татар укучыларына киң билгеле. Татар теленә 30 чуваш язучысының әсәрләре тәрҗемә ителгән.

СССР халыклары әдәбиятыннан татар теленә 30 үзбәк, 18 азербәйҗан, 12 белорус, 14 грузин, 12 казакъ, 13

латыш, 9 литва, 14 мари, 16 уйгур язучыларының әсәрләре тәрҗемә ителгән.

Татар телендә СССР халыкларының 54 милли әдәбиятыннан, фольклорыннан тәрҗемәләр басылган. Алар арасында бурят, калмык, кыргыз, кабардин, каракалпак, удмурт, чечен, әрмән, төрекмән, ногай, мордва һ. б. халыклар әдәбиятыннан тәрҗемәләр бар.

Илебез халыклары әдәбияты белән татар укучыларын таныштыру буенча башкарылган бу зур эшләр белән беррәттән әле күп кенә нәрсәләрнең эшләнмәвен дә күрми үтеп булмый.

Бай тарихы булган күп кенә милли әдәбиятлар белән татар халкын үз телендә таныштыру эшенең торышы хәзерге көн сорауларына җавап биреп җиткерә алмый. Мәсәлән, азербәйҗан әдәбиятының күп гасырлардан килә торган бай традициясе, зур тарихы бар. Дөньяга мәңге үлмәс әсәрләр биргән бу әдәбияттан ни бары 18 язучының әсәрләре генә тәрҗемә ителгән. Менә азербәйҗан халкының күренекле шагыйре Самед Вургун. Аның татар теленә бары ике генә шигыре тәрҗемә ителгән. Азербәйҗан язучыларыннан тик Низами, Рза Рәсүл, М. Хөсәен, Х.Мәһдинең әсәрләре генә аерым китап булып басылып чыккан. 15 язучының әсәрләре тик журналларда

гына басылган. Азербәйҗан әдәбияты классикларыннан, мәсәлән, Вакыйф, Фозули әсәрләренең татар телендә китап булып басылганы юк.

Шушы ук сүзләрне үзбәк, әрмән, казакъ, грузин, төрекмән, таҗик әдәбиятларына карата да әйтергә мөмкин.

Чит ил язучылары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эше Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк башлануга карамастан, революциядән соң гына киң күләмдә башкарыла.

Телебезгә француз әдәбияты күп тәрҗемә ителгән (В.Погон, Ж. Верн, А Барбюс, П.Беранже, Э.Золя, Мольер, Г.Габе, П Гамарра, В.Кутурье, Гра Феликс, Генриетта Вале, Жан Ришар Блок һ.б.).

Европа телләреннән татар теленә тәрҗемә ителү буенча икенче урында немец әдәбияты тора (Г.Гейне, И.Гете, бертуган Гриммнар, Шиллер, В.Бредель, Л.Фейхтван, Б. Келлерман,Э.М. Ремарк һ.б.).

Инглиз әдәбиятын татар теленә тәрҗемә итү буенча дә шактый эшләр башкарылган (Байрон, Этель Войнич, Даниэль Дефо, Свифт, Шекспир, Уида, Фрейдман, Редьярд Кпилинг һ.б.).

Америка әдәбиятыннан тәрҗемәләр дә (Бичер Стоу, Джек Лондон, Марк Твен, Эрнест Хемингуэй, Уолт

Уитмен, Агнес Смедли, Мэри Парке, Джон Рид, Теодор Драйзер, Майкл Гоулд һ.б.).

Шулай ук Италия, Испания, Дания һәм гарәп илләре әдәбиятыннан күп кенә әсәрләр татар теленә тәрҗемә ителә.

Бөек Ватан сугышыннан соң, халык демократиясе илләре әдәбиятларын татар теленә тәрҗемә итү шактый киң җәелеп китә: корея теленнән 31, вьетнам теленнән 20, чехословакия телләреннән 16, поляк теленнән 29, венгр теленнән 30, румын теленнән 9 язучы һәм шагыйрьнең әсәрләре тәрҗемәдә басыла.

Инде XX гасырның икенче яртысында, татар телендә беренче тапкыр буларак Куба, Бирма, Конго, Малайя, Гана, Гваделупа, Мадагаскар, Мозамбик, Пакистан, Сенегал, Сомали, Фил сөяге яры әдәбиятлары тәрҗемә ителә башлады.

Тәрҗемәләр аша татар язучылары Гарәп илләре әдәбияты (Мисыр, Сурия, Алжир, Тунис, Гыйрак, Ливан, Судан), төрек, һинд, иран, япон, норвег әдәбиятлары белән дә таныш.

XX гасырның беренче яртысында татар теленә чит ил әдәбиятларыннан 477 язучының әсәрләре тәрҗемә ителгән. Әсәрләре тәрҗемә ителмәгән 28 язучы турында

белешмәләр басылган, 12 сәнгать эшлеклесенең иҗат юлы яктыртылган. Революциядән соң татар телендә СССР һәм чит ил халыкларының 114 милли әдәбият һәм фольклоры әсәрләре тәрҗемә ителгән, барлыгы 1381 язучы һәм шагыйрьнең әсәрләре басылган. Шуның өстенә, әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителмәгән 78 язучы һәм 36 сәнгать эшлеклеләре турында татар матбугатында белешмәләр китерелгән.

Бездә матур әдәбият әсәрләре нигездә рус теле аркылы гына диярлек тәрҗемә ителеп килә. Хәтта кардәш төрки халыклар телләрендә язылган әсәрләрне рус теле аркылы тәрҗемә итү практикага кергән.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1***. *Дөнья күләм танылган күренекле фарсы шагыйре Гомәр Хәямнең робагыйларын укыгыз, анализ ясагыз. Тәрҗемәләрдә шул чор рухы сакланганмы? Татар әдәбиятында бу жанрда кемнәр иҗат итә?*

Калмады галәмдә мәгълүм булмаган,

Аз булыр әсрары мәрһүм булмаган.

Уйлагач җитмеш ике ел төн вә көн,

Аңладым: һичнәрсә мүгълүм булмаган (Дәрдмәнд тәрҗемәсе).

***

Берәү күкрәк кага-кага: «Бу – мин!» – ди,

Берәү байлыкка мактана: «Бу – мин!» –ди

Дәрәҗә, мал вә дан булды дигәндә,

Кинәт үлем килеп таба: «Бу – мин!» – ди (Нури Арсланов тәрҗемәсе).

***

О, бойся тело отдавать

На пищу горю и страданьям,

Томясь слепым любостяжаньем

Пред белым серебра сияньем,

Пред желтым златом трепетать!

Пока веселья час не минет

И теплый вздох твой

Не остынет –

Твои врага на пир тогда

Придет как хищная орда (перевод В.Величко).

## 4 НЧЕ ТЕМА. ТАТАР ТЕЛЕННӘН РУС ТЕЛЕНӘ ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Татар әдәбиятында әдәби тәрҗемә милли әдәбиятның бер өлешен тәшкил итә. Татар теленә беренче әдәби тәрҗемәләр (ирекле тәрҗемәләр) урта гасырларда ук

барлыкка килә. Мәсәлән, **Котб**, Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын тәрҗемә иткәндә, аның төп идея эчтәлеген, сюжетын һәм образларын, гомуми композициясен һәм кайбер поэтик формаларын саклап калып, шул ук вакытта әсәрне төркиләр тормышына, аларның дөньяны аңлауларына яраклаштыра. Шуңа күрә, «Хөсрәү вә Ширин»нең төркичәсен, бүгенге мәгънәдән чыгып, тәрҗемә дип атап булмый, бер үк вакытта ул оригиналь әсәр дә түгел, аны ярыморигиналь, ярымтәрҗемә әсәр дип атарга мөмкин. Котбның тәрҗемә принципларын дәвам иткән урта гасыр шагыйре **Сәйф Сараи** да Сәгъдинең «Гөлестан»ын төгәл тәрҗемә итми, ул аны кыскарта, үзгәртә: яңа мотивлар һәм вариацияләр кертә, үзенчәлекле сурәтләү чаралары куллана. Нәтиҗәдә, аның «Гөлестан би-т-төрки»е мөстәкыйль әдәби ядкәргә әверелә.

Тәрҗемәнең активлашуы 19 йөзнең ахыры – 20 йөзнең башында, ягъни милли әдәбиятның үсеш чорында күзәтелә, бу вакытта тәрҗемәләр оригиналь әсәрләр кебек үк кабул ителәләр. Бу чорда традицион рәвештә Шәрекъ әдәбияты әсәрләре: «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә» (**Габделгаллям Фәезханов** тәрҗ.), Низаминың «Ләйлә вә

Мәҗнүн»е (**Мәхмүт Максуд тәрҗ**.), «Мең дә бер кичә»се (**Фатыйх Халиди тәрҗ**.) һ.б. тәрҗемә ителә.

Үзе исән вакытта ук Г.Тукайның кайбер шигырьләре **Павел Александрович Радимов** тарафыннан рус теленә күчерелә. 1930 елларда рус теленә Шамил Усманов хикәяләре, М.Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары, 1940 елларда М.Әблиевнең «Шәмсекамәр», Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», Г.Камалның «Беренче театр» пьесалары, Ш.Камалның «Матур туганда» романы, Г.Тукайның, Һ.Такташның күп кенә шигырьләре, А.Алиш әкиятләре тәрҗемә ителә. 1960 еллар башына рус теленә тәрҗемәләр күбәя, М.Гафури, К.Нәҗми, Ә.Фәйзи, Г.Кутуй, М.Җәлил, Г.Әпсәләмов, М.Әмир, С.Хәким, Ә.Ерикәй, Г.Бәширов әсәрләре тәрҗемә ителә.

СССР күләмендә югары бәяләнгән, дәүләт бүләкләре алган әсәрләрне тәрҗемә итү бервакыт рәсми төс алган, сәясәткә әверелгән чаклар да булган. 1940-1950 елларда югары бәяләнгән андый әсәрләрне тәрҗемә итү мәҗбүри санала иде. Ул мәҗбүрилекнең безнең өчен уңай нәтиҗәләре дә булгалады. Нәкъ шул дәвердә 3 нче дәрәҗә Сталин премиясенә лаек дип табылган үз әсәрләребездән Г.Бәшировның «Намус»ы белән К.Нәҗминең «Язгы җилләр»е күпчелек Союздаш республика халыклары

телләрендә басылып чыктылар. Болгар, венгр, кытай, немец, поляк һ.б. телләрдә сөйләшүче әдәбият сөючеләр дә нәкъ шул елларда Совет чоры татар әдәбияты үрнәкләре белән таныша алдылар.

Совет чоры татар әдәби тәрҗемә өлкәсендә чын мәгънәсендә «алтын чор» булып таныла, бу дәвердә татар әдәбиятын күп кенә тәрҗемәләр белән баеткан тәрҗемә мәктәбе барлыкка килә. Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү өлкәсендә **Галия Хантимерова, Разия Фәизова, Азалия Бадюгина (прозада); Анна Ахматова, Семен Иванов, Александр Тарковский, Давид Самойлов, Семен Липкин, Ривим Моран, Михаил Зарецкий, Николай Беляев, Геннадий Паушкин, Ренат Харис, Равил Бохараев, Роза Кожевникова, Лидия Григорьева** һ.б. (поэзиядә) эшли.

**1972** елда Язучылар берлеге идарәсе рәисе Зәки Нури тырышлыгы белән Максим Горький исемен йөртүче әдәбият институтында татарчадан русчага тәрҗемә итүчеләр курсы оештырылды. Өметләр тулаем акланмаса да, ул төркемнән **Солтан Шәмси, Роза Баубекова-Кожевникова, Фирдәүс Әһлия** кебек каләм әһелләре тәрбияләнеп чыга. Укуын тәмамлагач ук, Солтан Шәмси классик әдибебез Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл

чәчәкләр» повестен һәм хикәяләрен тәрҗемә итеп бастыра. Мирсәй Әмир белән Ләбибә Ихсанованың аерым хикәяләрен вакытлы матбугатка эшләп бирә. Роза Баубекова да татар поэзия үрнәкләрен тәрҗемә итеп бастыру өлкәсендә зур абруй казана.

**Туксанынчы елларда** төрле-төрле нәшриятлар барлыкка килүенә карамастан, татар китабының язмышы, аңа булган мөнәсәбәт кискен үзгәрә. Ә тәрҗемә әдәбият чыгудан туктады дип әйтерлек. Чөнки китап сәүдәсенә бөтенләй дә әһәмият бирелми башлады. Татар әдәбиятын үз итүчеләр, яратып укучылар башлыча авылда яши. Авыл халкына хезмәт итүче төп сәүдә оешмасы элгәре елларда Татпотребсоюз җәмгыяте иде. Базар мөнәсәбәтләрен үзләштерәбез дигән сылтау белән иң әүвәл ул оешманың китап сәүдәсе бүлекчәсе бетерелде. Авылда түгел, хәтта ки район үзәкләрендә дә китап кибетләрен яптылар. Рухи халәт бик зәгыйфь. Һәм әлегә ул көннән-көн зәгыйфьләнә генә бара.

**Соңгы вакытта** рус теленә тәрҗемәләр әз-мәз күренгәли башлады. Кардәш милләтләрдән казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән һ.б. лар бүген татар язучысының китабын кулга тотып караудан бөтенләй мәхрүм ителгән. Татарстанда яшәүче рус телле «кардәшләребезнең» хәле

бераз җиңелрәк. Хәзер алар өчен Казанда елына ике-өч китап тәрҗемә ителә. «Идель», «Казань» кебек рус телле журналларда да аерым тәрҗемәләр күренгәли. Бу җәһәттән «Идель» журналының активрак булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ә Мәскәү нәшриятлары һәм журналлары әлегә безне танымый, тиң күрми. Киләчәктә чәчмә әдәбиятны русча тәрҗемәдә бастырып чыгаруны ике дәүләт нәшрияты – «Мәгариф» белән Татарстан китап нәшрияты җайга салыр бәлкем.

**Матур әдәбиятны рус теленә тәрҗемә итүчеләр** сафына сәләтле яңа көчләрнең килә башлавы да сөендерә. Мәсәлән, «Идель» журналы битләрендә **Фаяз Фәизев, Гадел Хәеров, Гәүһәр Мәһдиева-Хәсәневалар**ның тәрҗемә хезмәтләре ешрак күренә башлады. Гәүһәр Мәһдиеваның «Идель»дән тыш Мәскәүдә чыгучы «Современник» журналында күренгәләп китүе дә сөендерә. Соңгы вакытларда ул Аяз Гыйләҗев, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла һ.б. лар хикәяләрен, Фәнис Яруллинның «Йөртә безне язмышлар» повестен рус телле укучы хөкеменә тапшырды. **Булат Хәмидулинның** тәрҗемәләре дә ешрак күренә башлады. 2001 елда ул Гариф Ахуновның соңгы елларда иҗат иткән өч повестен берләштергән «Тимерханның күргән-кичергәннәре» китабын, 2005 елда

Вакыйф Имамовның «Казан каласы» романын нәшер итте. «Дәрдемәнд» фотоальбомын чыгаруда да тәрҗемәче буларак катнашты. Ара-тирә аның хезмәтләре вакытлы матбугат битләрендә дә күренгәләп китә. Соңгы вакытта Язучылар берлеге каршында теркәлгән тәрҗемәчеләр секциясе эшендә актив катнашкан **Наилә Краеваның** да уңышлары күзгә ташланырлык. Рус телле әдәбият сөючеләр хөкеменә аның тәрҗемәсендә Фатих Хөсни, Гариф Галиев хикәяләренең кечерәк тупламалары тәкъдим ителде. Аның Айдар Хәлим белән җитди хезмәттәшлек итә башлавы турында да мәгълүмат бар. Ишетеп белүемчә, Айдарның бер китабы инде аның тәрҗемәсендә басылган да. Мәскәүдә яшәп иҗат итүче **Венера Вәлиеваны** әле санап үтелгән яшьләр рәтенә кертеп булмый, билгеле. Әмма аның Габдулла Тукай шигырьләрен дистә еллар дәвамында эзлекле рәвештә тәрҗемә итәргә алынуын хупларга кирәктер.

**Соңгы елларда** тәрҗемә эше буенча «Татнефть» акционерлык җәмгыяте карамагында оештырылган «Рухият» фонды зур эшләр башкара. Онытылып барган татар әдипләренең, татар галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләренең китапларын нәшер итеп, халыкка, китапханәләргә тарата. Андый мактаулы эшләрне

оештыруда күренекле академигыбыз Миркасыйм Госмановның өлеше дә зур. «Рухият» һәм «Җыен» фондлары нәшер итеп чыгарган милли әдәби-иҗтимагый мирасыбызның байтагы аның кайгыртуы һәм оештыруы нәтиҗәсендә дөнья күрде.

Бүгенге көндә, бәлки, татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен рус, инглиз, француз, гарәп һ.б. телләргә тәрҗемә итү эше белән шөгыльләнердән махсус бер төркем булдыру кирәктер. Тәрҗемәчеләрне табу, яллау, кирәк чакта сүзгә-сүз тәрҗемәләр булдыру, нәшриятлар һәм сәүдә оешмалары белән килешү төзү – хәзерге заманда булдыклы бер башкаручы төркем оештыруны сорый. Ул төркем Язучылар берлеге кул астында яисә әлеге фәнни институт карамагында булырга мөмкин.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1**. М.Сәфәровның “Якты сукмак” мәкаләсен укып фикер алышыгыз.*

***2**. Равил Бохараевның рус теленә тәрҗемәләрен укыгыз. Тәрҗемәнең синтаксик-стилистик оешуы, мәгънәсе белән оригиналга ни дәрәҗәдә тәңгәл килүен аңлатыгыз.*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ “РОДНОЙ ЯЗЫК”

О язык родной, певучий, о родительская речь!
Что еще на свете знал я, что сумел я уберечь?

Колыбель мою качая, тихо-тихо пела мать.
Подрастая, сказки бабушки я начал понимать.

О язык мой, мы навечно неразлучные друзья,
с детства стала мне понятна радость и печаль твоя.

О язык мой, как сердечно я молился в первый раз:
Боже, – я шептал, – помилуй мать, отца, помилуй нас.

## ДЭРДМЕНД

Лето ушло.
Осень настала, – снежным дождем потянуло.
Заводи взор голубой
льдом затянуло.
Роза увяла.
Стеблем сухим – обида осталась.
Соловей,
Тебе одна лишь колючка досталась.

## МУСА ДЖАЛИЛЬ “ПЕРЕЖИТОЕ”

Все, что мучило сердце,
с течением лет

исцеленной душе
не покажется злом.

Минет ночь, и печаль,
чуть забрезжит рассвет,
часто сходит на нет,
исчезая в былом.

Но осталось с тобой
навсегда, навсегда
все, что счастьем звалось,
зов родных голосов.

Пламенея, душа
сбережет для тебя
радость мирных минут,
свет счастливых часов.

## 5 НЧЕ ТЕМА. РУС ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

Татар теленә иң күп тәрҗемә ителгән әдәбият – бөек гуманизм, азатлык идеяләре белән сугарылган, дөньяда иң алдынгы классик рус әдәбияты.

Рус теленнән татар теленә матур әдәбият әсәрләрен беренчеләрдән булып **Мартиньян Иванов** тәрҗемә иткән.

1842 елны М. Ивановның “Татар хрестоматия”сендә татар теленә Иван Иванович Хемницер, Иван Иванович Дмитриев, Иван Александрович Крылов әсәрләре тәрҗемә ителә. **Каюм Насыйри** – Л.Н.Толстой әкиятләрен, И.А.Крылов мәсәлләрен, **Таиб Яхин** – А.С.Пушкин, А.Н.Афанасьев әкиятләрен; **Мөхәммәтсәлим Өметбаев** А.С.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны»н тәрҗемә итә. 19 гасыр ахырында А.С.Пушкин тәрҗемә ителә башлый. Мәсәлән, аның “Бакчасарай фонтаны”, “Балыкчы һәм балык турында әкият”, “Кышкы юл” шигыре, “Евгений Онегиннан” өзекләр һ.б. тәрҗемә ителә. Ул чордагы актив тәрҗемәчеләр: **Гаяз Исхакый**, **Габдулла Тукай**, **Сәгыйть Рәмиев**, **Галиәскәр Камал**, **Солтан Рахманкулов**, **Идрис Багданов** һ.б.

Тәрҗемәләр, кагыйдә буларак, ирекле рәвештә эшләнә. Күп очракта оригиналь әсәрнең авторы яки исеме күрсәтелми (мәсәлән, «Шиллердан» дип кенә язалар). Аерым очракларда укучы тәрҗемәне тәрҗемәченең үз әсәре итеп кабул итә.

Татар теленә тәрҗемә тарихы бөек шагыйрь **Габдулла Тукай** исеме белән бәйле. Тукай мәдрәсәдә укыган елларда ук Крыловның 75 мәсәлен тәрҗемә иткән. Соңрак Г.Тукай Пушкин, Лермонтов, Жуковский, Фет,

Тютчев, Майков, Ушинский, Кольцов һәм башка язучыларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Тәрҗемәнең дәүләт күләмендә зур эш булып китүе Октябрь революциясеннән соңгы елларга туры килә. Иҗтимагый-сәяси, фәнни әдәбиятны әдәбиятны тәрҗемә итү белән бергә матур әдәбиятны тәрҗемә итү эше дә киң колач ала. Р.Юсупов хезмәтләрендә китерелгән русчадан татарчага тәрҗемә белән бәйле кайбер саннарны карап китик:

– 1918 елдан 1968 елга кадәр 1600 матур әдәбият әсәре тәрҗемә ителгән.

– 1918-1962 елларда элекке СССРдагы һәм чит илләрдәге 114 халыкның матур әдәбият һәм фольклор әсәрләре тәрҗемә ителгән.

– 1380 нән артык язучының әсәре тәрҗемә ителгән.

40-50 елларда Сталин премиясе алган һәр әсәрне тәрҗемә итү гадәткә кереп китә. Тәрҗемә ителән әсәрләрнең күпчелеге рус һәм чит ил әдәбиятыннан. Татар теленә чыккан әсәрләренең күплеге буенча беренче урында А.М. Горький тора. 1918-1962 елларда аның әсәрләре татар телендә 64 тапкыр басылып чыккан. А.С.Пушкин – 53 тапкыр, Л.Н.Толстой – 34 тапкыр, А.П.Чехов – 21 тапкыр, И.С.Тургенев – 15, М.Ю.Лермонтов – 14 тапкыр

бастырыла. Шулай ук Самуил Маршак, Алексей Толстой, Николай Гоголь, Николай Некрасов, Владимир Маяковский, Аркадий Гайдар, Михаил Шолохов, Вячеслав Шишков һәм башка язучыларның да китаплары татар теленә берничә тапкыр тәрҗемә ителә.

Бу чор әдәби тәрҗемәгә тәңгәл тәрҗемәгә омтылу хас. Рус классик әдәбиятыннан тыш, совет әдәбияты үрнәкләре дә тәрҗемә ителә: Алексей Толстой, Вячеслав Шишков, Александр Фадеев, Михаил Шолохов, Дмитрий Фурманов, Николай Островский, Илья Эренбург, Вера Панова, Константин Паустовский, Николай Погодин, Константин Симонов, Михаил Пришвин, Александр Твардовский, Николай Тихонов; балалар әдәбиятыннан Сергей Аксаков, Павел Бажов, Владимир Короленко, Самуил Маршак, Сергей Михалков, Агния Барто, Виталий Бианки, Аркадий Гайдар, Борис Житков, Вениамин Каверин, Лев Кассиль, Валентин Катаев, Николай Носов һ.б. әсәрләре.

Бер үк әсәр берничә тәрҗемәче тарафыннан эшләнеп, төрле вариантларда басылу фактлары бар. Шундый мисаллар күрсәтергә мөмкин: А.С.Пушкинның беренче Фәтхи Бурнаш тарафыннан тәрҗемә ителгән “Евгений Онегин” романы соңыннан Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Исхак,

Шәйхи Манннур тәрҗемәсендә басылып чыккан. А.С.Пушкинның “Кышкы кич” шигыренең өч варианты бар: Мөхәммәт Садри, Әхмәт Ерикәй, Салих Баттал тәрҗемәләрендә; М.Горькийның “Ана” романы башта Фәтхи Бурнаш тәрҗемәсендә, аннары Мәхмүд Максуд тәрҗемәсендә чыккан. Грибоедовның “Акыллылык бәласе”н башта Нәкый Исәнбәт, Соңыннан Габдулла Шамуков тәрҗемә иткән. Билгеле бу тәрҗемәләрнең һәркайсында үзенчәлекле яклар бар, һәркайсында тәрҗемәчеләрнең уңышлары, иҗади йөзе чагыла

Совет чоры татар әдәби тәрҗемә өлкәсендә чын мәгънәсендә «алтын чор» булып танyла, бу дәвердә татар әдәбиятын күп кенә тәрҗемәләр белән баеткан тәрҗемә мәктәбе барлыкка килә: **Кәшфи Басыйров, Сәрвәр Әдһәмова, Ибраһим Гази, Абзал Шамов, Кыям Миңлебаев, Рәис Даутов, Вакыйф Зыятдинов, Фәния Гайнанова, Яхья Халитов, Таһир Нурмөхәммәтов, Саимә Ибраһимова, Лирон Хәмидуллин (прозада); Әхмәт Фәйзи, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Исхак, Нури Арсланов, Салих Баттал, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Әнвәр Давыдов, Мостафа Ногман, Зәки Нури, Марс Шабаев, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим (поэзиядә); Зәйни Солтанов, Габдулла Шамуков**

(драматургиядә) үзләрен татар теленә тәрҗемә итү осталары итеп таныталар. 1960 еллар башына классик рус һәм совет әдәбияты әсәрләренең бик күбесе тәрҗемә ителә. 1990 еллардан башлап, илнең икътисади хәленә бәйле рәвештә, тәрҗемә эшчәнлеге сүлпәнәя төшә.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1**. А.С.Пушкинның "Зимний вечер" шигыреннән алынган өзекнең тәрҗемәләрен чагыштырыгыз. Чорга хас тел үзенчәлекләре ни дәрәҗәдә чагылыш табуын мисаллар нигезендә дәлилләгез.*

Зимний вечер

Буря мглою небо кроет,
Вихри снежные крутя;
То, как зверь, она завоет,
То плачет, как дитя,
То по кровле обветшалой
Вдруг соломой зашумит,
То, как путник запорздалый,
К нам в окошко застучит (А.С. Пушкин, 1825).

Кышкы буран

Күкне тәмам каблаган
Буран караңгылыгы.
Карлы давыл бүредәй

Улый, баладай җылый,
Иске түбәгә менеб,
Шаулата саламларын,
Гәһ1 кичекгән юлчы күк,
Кага тәрәзә рамларын  (Г.Рахманколый, 1906).

Кышкы төн

Буран өермә бөтерәдер,
Кышкы кич
Күкне буран чорнап ала,
Гәһ – әле, кайчак, кайчакта.
Уйный, кар җирдән ала;
Йә җанварлардай үкерәдер,
Йә егълый гүя бала.
Йә бер крыша ябучыдай,
Түбә саламын чәчә,
Йә кич калган бер юлчыдай,
Тәрәзә капкачын әчә (Дәрдмәнд, 1900).

Кышкы кич

Ак карларны туздыра.
Я бала кебек елый ул.
Я ерткычтай ыжгыра.
Я менә дә өй башына
Саламны селкетә ул,

Я соңлаган юлчы кебек,
Тәрәзәне чиртә ул (Ә.Ерикәй, 1940).

Өермәләр күкне каплый,
Җил карларны бөтерә,
Я балалар төсле елый,
Я ерткычтай үкерә.
Я ул түбәнең тузгыган
Саламын кыштырдата,
Я ул кичеккән юлчыдай,
Тәрәзә шакылдата  (С.Баттал, 1949).

Кышкы кич

Каплый күкне җил дә давыл,
Кар, буран уйнап йөри,
Бер бүре кебек улый ул,
Бер бала кебек елый.
Я кинәт кыштырдый капшап, -
Йорт саламын туздыра,
Я шакый тәрәзәне, охшап
Соңга калган юлчыга (М.Садри, 1949).

# 6 НЧЫ ТЕМА. ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЛЕВ ТОЛСТОЙ ӘСӘРЛӘРЕ

Бөек рус язучысы һәм педагогы Лев Николаевич Толстойның Казан, татар халкы белән бәйләнеше шактый зур. Ул 1841-1847 елларда Казанда яши, Казан университетының философия һәм юридик факультетларында белем ала. Алга таба рус, бөтендөнья әдәбиятын баеткан роман, драма, повесть, хикәя, истәлекләр һ.б. жанрлардагы әсәрләрен яза, педагогик эчтәлекле хезмәтләр, дәреслекләр тудыра.

Л.Н.Толстой Русиядә яшәгән төрле милләт халыклары язмышы, аларның матур киләчәге турында даими кайгыртып яшәгән затларның берсе булды. Әсәрләре Русиядәге бик күп милләт халыклары теленә дә тәрҗемә ителгән һәм әле дә тәрҗемә ителә. Танылган сүз остасының иҗаты белән татар укучыларын таныштыра башлауның йөз елдан артык тарихы бар. Әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән әдипләрнең беренчесе И.А.Крылов, икенчесе Л.Н.Толстой була.

Әдип-педагогның балалар өчен язылган аерым хикәяләрен беренче тапкыр татар теленә XIX гасыр ахырында танылган мәгърифәтчеләр К.Насыйри, Т.Яхин һ.б. тәрҗемә итә һәм аларны үзләре төзегән төрле

җыентыкларга, уку кулланмаларына кертәләр. XX гасыр башында исә бу изге гамәлләрне Г.Тукай, М.Мәрҗани, Н.Думави, Ф.Агиев һ.б. әдипләр дәвам итә.

XIX гасыр ахырында Лев Николаевичның "Крейцер сонатасы", "Беренче шәрабчы" әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә, әмма аларны патша цензурасы басарга рөхсәт бирми.

Беренче рус революциясе башлану белән (1905-1907 елларда), цензураның азмы-күпме көче кими, цензурасыз басу да гамәлгә керә. Шушы чорда Л.Н.Толстой әсәрләре дә татар телендә шактый күп басыла башлый.

1908 елда аның биш китабы, ә 1910 елда берничә әсәре татар телендә аерым китап булып дөнья күрә.

Октябрь борылышына кадәр бөек сүз остасының нинди әсәрләре тәрҗемә ителгән соң?

Шундый китапларның иң күренеклеләреннән Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемәсендә "Кавказ әсире" (1908), драматург һәм педагог Идрис Богданов тәрҗемә иткән "Корней Васильевич" (1909), "Крейцер сонаты" (1912), Сәгыйть Рәмиев тәрҗемәсендә "Тере мәет" (1911), Мәхмүт Галәү тәрҗемә иткән "Хаҗи Морат" (1913) һ.б. санала.

Л.Толстойның Октябрьгә кадәр һәм аннан соң татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләренең шактый өлешен балалар өчен иҗат ителгән җимешләре тәшкил итә.

Татар әдипләре һәм тәрҗемәчеләре аның балалар өчен язган әсәрләрен аеруча яратып тәрҗемә иткәннәр. Бу өлкәдә бөек Г.Тукайның хезмәте гаять зур. Ул Лев Николаевичның шактый тирән эчтәлекле, тәрбияви кыйммәткә ия булган кыска хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә һәм аларны "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре", "Яңа кыйраәт" исемле дәреслекләренә, өстәмә уку китапларына кертә. 1906 елда Г.Тукай "Фикер" газетасында Л.Толстойның сәяси эчтәлекле, башкорт җирләрен талау һәм башкорт халкының авыр хәле турында сөйләүче "Ильяс" хикәясен, шунда ук " Бик кыйбат" әсәрен тәрҗемә итеп бастыра.

1909-1913 елларда Л.Толстойның "Җиләкләр", дидактик эчтәлекле "Толстой хикәяләре", "Толстой бабай хикәяләре", "Тугрылыклы казый", "Ни чәчсәң, шуны урырсың", "Шайтан илә игенче", "Олылык нәрсәдә?" һ.б. китаплары татар телендә басыла.

Мәшһүр китап белгече, академик Әбрар Кәримуллин раславынча, 1905-1917 елларда Л.Н.Толстойның әсәрләре татар телендә 30 китап буларак дөнья күрә.

1908 елда аның биш китабы, ә 1910 елда берничә әсәре татар телендә аерым китап булып дөнья күрә.

Шунысы куанычлы: Октябрь борылышына кадәр татарлар Л.Н.Толстой әсәрләрен төрки халыклар арасында беренче булып үз телләрендә басу эшен башлап җибәргәннәр.

Октябрь борылышы бөек фикер иясенең күләмле әсәрләрен татар укучысына җиткерү мөмкинлеген тудырды. 1935 елда Сәрвәр Әдһәмова "Кавказ әсире", "Алпавыт иртәсе", "Балдан соң" әсәрләрен тәрҗемә итә. Фәтхи Бурнаш тәрҗемәсендә "Хаҗи Морат", Абдулла Әхмәт тәрҗемәсендә балалар өчен хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Күренекле язучы һәм тәрҗемәче Мәхмүт Максуд бөек рус әдибенең "Сугыш һәм тынычлык" эпопеясын, "Анна Каренина" романын зур осталык белән тәрҗемә итә. Афзал Шамов тәрҗемәсендә өч басмада "Яңадан туу" романы укучыга җиткерелә. Бөек талант иясенең "Казаклар", "Балачак", "Үсмерчак", "Егетлек" повестьларын татарчалаштырып, сәләтле тәрҗемәче Кыям Миңлебаев та изге гамәл башкарды.

Л. Толстойның Октябрь борылышыннан соң басылып чыккан 37 китабының унбишләбе балалар өчен иҗат ителгән. Алар арасында "Бульба" (Ш. Максутова

тәрҗемәсе), "Бүре һәм кәҗә бәтие" (С. Сабиров тәрҗемәсе), "Ике иптәш", "Кечкенә хикәяләр", "Мәсәлләр һәм кыска хикәяләр", "Фил", "Хайваннар турында хикәяләр", "Хикәяләр һәм әкиятләр", "Әлифбадан хикәяләр", "Өч аю", "Нәниләргә" һ.б. җыентыклар бар. Бөек рус язучысының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүгә Ә.Еники, А.Гыйләҗев, А.Гомәр, Ә.Камал, Ф.Басыйров, Ф.Фасеев кебек сүз осталары, тәрҗемәчеләре дә җитди өлеш керттеләр.

Л.Толстойның бай әдәби мирасы, татар теленә тәрҗемә ителгән кыйммәтле әсәрләре татар укучысын, бигрәк тә яшь буынны гуманистик рухта тәрбиләүдә, аның эстетик зәвыгын баетуда бай чыганак ролен үти.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1***. *Л.Н.Толстойның "Юность" әсәрендә кулланылган реалияләрне табыгыз һәм тәрҗемәдә биерелешен тикшерегез.*

1) Он сшил себе модное платье – оливковый фрак, модные  панталоны со штрипками и длинную бекешу, которая очень шла к нему… – Папа үзенә модалы киемнәр – яшькелт-сары фрак белән тасмалы, модалы панталон, өстендә ятып торган озын бекеша (биле бөрмәле бишмәт)

тектерде... 2) Теперь она мечтала уже выйти замуж не за гусара, а за певца или музыканта и с этой целью усердно занималась музыкой. – Хәзер инде ул, гусарга чыгам дип түгел, бәлки берәр җырчыга яки музыкантка чыгам, дип хыяллана һәм шуңа күрә музыкага чынлап торып өйрәнә иде. 3) Духовник стал перед налоем и медленно обратил ко мне свое лицо. –Тәүбә кылдыручы налой (иконалар һәм дини китаплар куя торган авыш өстәл) алдында тора иде, ул ашыкмый гына миңа таба борылды. 4) Я узнал от Николая, потому что папа ничего не рассказывал нам про свои игорные дела, что он особенно счастливо эту зиму; выграл что-то ужасно много, положил деньги в ломбард и весной не хотел больше играть. – Мин бу кышны папаның картадан бәхете булганын Николайдан ишеттем, чөнки папа үзе уйнавы хакында безгә бер сүз сөйләмәс иде, искиткеч күп откан акчасын да ломбардка салган, ә язын башка уйнамаска булган (К.Миңлебаев тәрҗемәсе).

## 7 НЧЕ ТЕМА. ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ТӘРҖЕМӘЛӘРДӘ КӨНБАТЫШ ӘДӘБИЯТЫ

Татар әдәбияты, башка халыклар әдәбияты кебек үк, күп дәверләр үткән. Аның эчтәлеген һәм үсеш баскычларын иң элек, әлбәттә, халык тормышындагы иҗтимагый-сәяси һәм

икътисади шартлар билгели. Моннан тыш, башка милләтләрнең әдәбиятлары белән багланышлар да үз өлешен кертә. Мәгълүм булганча, татар әдәбияты озак гасырлар дәвамында көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә формалаша, үсеп җитлегә һәм аның гүзәл бер үрнәге рәвешендә яши. XIX гасырда шәрык әдәбиятыннан тыш аңарда рус әдәбияты тәэсире сизелә башлый, ә XX гасыр башында бу процесс киң колач җәя. Узган гасыр башы татар әдәбияты тарихында, Л.Н.Толстой, А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, И.А.Крылов, И.С.Тургенев кебек рус язучыларының әсәрләре белән беррәттән, көнбатыш әдәбиятларыннан да тәрҗемәләр шактый арта.

Татар халкында көнбатыш әдәбияты белән кызыксыну XIX гасырда ук сизелә. Ләкин әлеге әдәбиятның татар арасына керүенә, Г.Баттал сүзләре белән әйтсәк, "*бик калын бер рус дивары*" комачаулый. Әмма бу "дивар" көнбатыш әдәбиятын үзләштерүне озак тоткарлый алмый, XX йөз башында көнбатыш әдәбияты татар укучысына барып җитә. Барлык газета-журналларда диярлек көнбатыш әдәбияты тарихы, әсәрләре яисә аерым язучыларның тормыш юллары һәм иҗатлары турында мәгълүматлар бирелә башлый.

20 йөз башында татар әдәбиятына рус һәм төрек әдәбиятлары аша Көнбатыш Европа әдәбияты әсәрләре керә башлый. Мәсәлән, француз әдәбияты татарларга төрек әдәбияты аша килеп ирешә. Татар теленә тәрҗемә ителгән беренче Көнбатыш Европа әдәбияты әсәре – Даниэль Дефоның «Робинзон Крузо» романы (**Садри Максуди тәрҗ**., 1898). 20 йөз башында **Фатыйх Әмирхан** Ганс-Хрестиан Андерсен әкиятләрен, **Рәкыйб Рәкыйби** Ги де Мопассанның «Милон атакай» («Папаша Милон») хикәясен, **Сәгыйть Рәмиев** Фридрих Шиллерның «Перчатка» балладасын, **Нәҗип Думави** Вольтерның «Мегаполис» повестен, **Галиәскәр Камал** Мольерның «Саран» («Скупой») пьесасын, Александр Дюма-улының «Камелияле ханым» («Дама с камелиями») романын һ.б. тәрҗемә итәләр.

1901-1917 еллар аралыгында алман, испан, поляк, инглиз, француз һ.б. милләтләрнең әдәбият җәүһәрләре татар теленә тәрҗемә ителеп басыла. Аерым китап рәвешендә дөнья күргән, тиражы 81 700 данә булган (6 китапның тиражы билгесез), 33 басма, 25 исемдәге китап дөнья күрә (бу санга махсус балалар өчен басылган китаплар кертелмәде).

Француз әдәбиятыннан 7 исемдәге китап тәрҗемә ителә, америка әдәбиятыннан – 6, алман әдәбиятыннан – 4, инглиз һәм италия әдәбиятларыннан икешәр, испания, норвегия һәм польша әдәбиятларыннан берәр исемдәге китап нәшер ителә.

Моннан тыш, "Хикәя нафига" исемле китап басыла. Әлеге җыентыкка Эзоп (грек) белән Лафонтенның (француз) мәсәл һәм хикәяләре кергән, шул сәбәпле, милләт ягыннан без аны катнаш туплама буларак карыйбыз. "Хикәя нафига"ның тагын бер үзенчәлеге бар, фәкать шушы китап кына җыентык рәвешендә басылган, калганнары монобасмалар.

Соңгы вакытларга кадәр XX йөз башында татар халкы дини китаплар гына укыган, дигән фикер яшәп килде. Алда китерелгән саннардан күренгәнчә, татар кешесе көнбатыш әдәбияты үрнәкләре белән туган телендә таныша алган.

Чит ил язучылары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эше Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк башлануга карамастан, революциядән соң гына киң күләмдә башкарыла.

Телебезгә француз әдәбияты күп тәрҗемә ителгән. Француз әдәбияты классикларыннан В.Гюгоның "Туксан өченче", "Хокуксызлар" романнарын һәм хикәяләрен,

Жюль Вернның "Капитан Грант балалары", "Серле утрау", "80 мең километр су астыннан" кебек мәшһүр әсәрләрен, Анти Барбюс әсәрләрен, Пьер-жан Дэ Беранже шигырьләрен, Эмиль. Золя романнарын, Мольер комедияләрен, Ромен Роллан әсәрләрен татар укучылары үз ана телендә укый. Татар теленә тәрҗемә аркылы укучылар Ги де Мопассан, Пьер Гамарра, Гра Феликс, Генриетта Вале, Жан Ришар Блок һ.б. француз язучылары белән танышалар.

Европа телләреннән татар теленә тәрҗемә ителү буенча икенче урында немец әдәбияты тора. Туган телебезгә Генрих Гейненың "Германия"се, Иоган Гетеның "Фауст"ы, "Төлке хәйләләре" җыентыгы, бертуган Гриммнарның әкиятләре, Шиллерның "Вильгельм Телль" драмасы, "Мәкер һәм мәхәббәт", "Юлбарыслар" трагедияләре, Вилли Бредельның "Сыналу", Леан Фейхтванның "Оппенгеймнар семьясы", Бернгард Келлерманның "9 январь", Эрих Мария Ремаркның "Көнбатыш фронтында үзгәрешләр юк" романнары һ.б. әсәрләр тәрҗемә ителгән. Немец әдәбиятыннан 32 язучының әсәрләрен татарча укырга мөмкин.

Инглиз әдәбиятын татар теленә тәрҗемә итү буенча дә шактый эшләр башкарылган. Байронның "Шильон

тоткыны" поэмасы аерым китап булып басылган һәм шагыйрьнең башка күп шигырьләре тәрҗемә ителә. Этель Войничның "Кигәвен" романы ике тапкыр, Даниэль Дефоның "Робинзон Крузо"сы 3 тапкыр, Свифтның "Гулливер лилипутлар арасында" әсәре 2 тапкыр басылган. Шекспирның "Гамлет", "Король Лир", "Отелло", "Ромео һәм Джульетта" трагедияләре һәм "Сонетлары", Уида, Редьярд Кпилинг әсәрләре аерым китаплар булып чыкканнар.

Америка әдәбиятыннан тәрҗемәләр Бичер Стоуның "Том агай алачыгы", Джек Лондонның "Бүре", "Лондон төпләрендә", "Сер", "Чыныгу" һ.б. хикәяләре, Э.Синклерның "Джимми Хиггинс" романы, Марк Твенның "Том Сойер маҗаралары", "Янки король Артур сараенда" исемле әсәрләре, Эрнест Хемингуэй, Уолт Уитмен, Агнес Смедли, Мэри Парке, Джон Рид, Теодор Драйзер, Майкл Гоулд һ.б. әсәрләре татар телендә дөнья күрә.

Басма саны ягыннан беренчелекне инглиз язучысы Даниэль Дефо ныклы рәвештә саклап килә. Аның Робинзон Крузо турындагы маҗаралы сюжетка корылган әсәре XIX гасырда ук татар телендә дөнья күрә, ә XX йөз башында аның 7 басмасы билгеле, ул 15000 данә тираж белән дөнья күрә. Даниэль Дефоның "Робинзон"ы татар теленә

турыдан-туры инглиз теленнән күчерелми, ә рус тәрҗемәсе аша татарчалаштырыла.

Басма саны ягыннан икенче урынны Нат Пинкертон маҗаралары тора. "Робинзон" шикелле үк, Нат Пинкертон турындагы әсәрләр дә маҗаралы сюжетка корылган. "Редирзон утравында "Җеннәр" исемле китапның кереш сүзендә тәрҗемәче бу әсәр турында болай яза: "Аның вакыйгалары "Мең дә бер кичә" хикәясе белән бердер. Аерма бары шунда гына "Нат Пинкертонның башыннан узган эшләре җөмләсендән ошбу гасырда булган эшләрдер". Димәк, XX йөз башында татар әдәбиятында маҗаралы сюжетка корылган әсәрләр җитмәве сизелә, һәм татарлар арасында танылган "Мең дә бер кичә" шәкелендә язылган шәрык әсәрләре генә татар әдәбияты мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә алмый. Әлеге җитешсезлекне бетерү максатыннан булса кирәк, алда телгә алынган әсәрләрдән тыш, Жюль Вернның "Серле утрау" һәм башка китаплар басыла, аларның басма саны 12 гә җитә.

Татар телендә чыккан көнбатыш әсәрләре татар әдәбиятына яңа темалар, идеяләр алып киләләр, XX гасырның башларында тарихилыкка, тарихи үсешкә, аның закончалыклары аша киләчәкне күз алдына китерү

кызыксындыра, әлеге шартларда Гульярдоның "Айга сәяхәт" исемле әсәре татар телендә басылу гаҗәп түгел. Г.Тукайның "Китмибез" шигыренә аваздаш булып, 1908 елда поляк язучысы Генрик Сенкевичның "Диңгез артында" исемле әсәре татарлар арасында Төркиягә китү идеясе алга сөргән вакытта басыла.

Яңа темалардан тыш, көнбатыш әдәбияты жанрларны үстерүгә дә зур өлеш кертә, мәсәлән, трагедия жанрының үзенчәлекләрен татар укучысы Фридрих Шиллерның "Мәкер вә мәхәббәт"е, Генрих Гейненың "Әл-Мансур"ы белән, ә мелодраманы Дейвид Аннерeның "Хөкемдә хаталык" аша үзләштерә.

Жанр ягыннан исә, XX йөз башышда көнбатыш әдәбияты әсәрләреннән поэзиягә караган бер генә китап нәшер ителгән, ул – Байронның "Мәхбүсе", 1911 елны Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемәсендә 3000 данә тираж белән "Шигырь китапханәсе" сериясендә басыла. Китапны тәрҗемә итүдә Габдулла Тукай да катнаша, бу турыда Сәгыйть Сүнчәләй китапның икенче басмасының кереш сүзендә яза.

Драматик жанрларны үстерү юлында, алда телгә алынган әсәрләрдән башка татар телендә Брейның "Бозыклар" драмасы, Дюфрейның "Гашыйг" ы, Сәед

Яхъяның "Хикәят залим ачлык" кебек әсәрләре басыла. Драматик жанрда 8 китап бар. Калганнары барысы да проза жанрына карый.

Димәк, XX йөз башы татар әдәбиятының проза жанрын үстерүгә ихтыяҗ зур була. Шуңа күрә дә тәрҗемә әсәрләрнең 72% -ы проза әсәрләре.

1908 елны үзенә күрә "уяну елы" дип атап була: шул елда гына 9 исемдәге китап басыла, аларның тиражы 30 900 данә, бу 17 ел дәвамында басылган китапларның 36%-ын тәшкил итә. Кызганыч, бу процесс алга таба үсүен дәвам итми.

Көнбатыш әдәбияты татар халкына берничә юл белән керә: иң күбесе – рус теле аша, ягъни башта рус теленә тәрҗемә ителеп, аннары татарчалаштырылганнар, алар арасында Даниэль Дефоның "Робинзон"ы, Генрик Сенкевичның "Диңгез арты" һ.б.; икенчесе – төрек теле аша, мисал итеп Мольерны китерергә була; өченчесе – оригиналдан, тәрҗемәләр бу эштә дә рус тәрҗемәләренең кулланылуы очрый, мәсәлән, Генрих Гейненың " Әл-Мансур"ын Сүнчәләй тәрҗемә иткәндә Миллер белән Михайлов басмаларына мөрәҗәгать итә.

Көнбатыш әдәбияты үрнәкләрен татар халкына җиткерүчеләр турында да әйтергә кирәк, тәрҗемәчеләрнең

кайберләрен санап үтик: басма саны ягыннан иң активы **Н.Н.**, ул Д. Дефоның "Робинзон"ын татарчалаштыра, аның барлыгы 6 басмасы билгеле; тәрҗемә ителгән китаплар саны һәм тираж ягыннан беренчелекне **С.Сүнчәләй** тота, ул Байронның "Шильон Мәхбүс"ен, Г.Генрихның "Әл-Мансур"ын, Г.Сенкевичның "Диңгез артында" исемле китапларын тәрҗемә итеп бастыра; **Г.Камал** Д. Аннереның һәм Кормонның "Хөкемдә хаталык", шулай ук Дюфрей Морис белән Руссо Жакның "Гашыйк" исемле драматик әсәрләрен тәрҗемә итә. Шулай ук Д.Гөбәйди, И.Богданов, В.Апанаев, С.Рахманкулов, М. Фәйзи, Ф.Халидиләр актив эшли. Аларның күбесе – татар дөньясында танылган шәхесләр. Тәрҗемәчеләрнең төгәл исемлеген бүгенге көндә әйтеп булмый, чөнки аларның күбесе аббревиатура белән чикләнә: **Н.Н.** һәм **Д.Г.** дип язылган яки бөтенләй тәрҗемәче турында бернинди мәгълүмат бирелмәгән китаплар бар.

СССР һәм чит дөнья халыклары әдәбияты үрнәкләрен татар телендә чыгаруда актив эшләүче язучылардан дистәләгән роман вә повестьлар тәрҗемә иткән **Рәис Даутов, Яхъя Халитов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Әнәс Хәсәнев, Шәһидә Максудова, Фәния Гайнанова, Наилә Вәлитова, Люция Нәҗмиева,**

**Фәрваз Миңнуллин, Ясыйр Шәмсетдинов** һ.б.билгеләп үтәргә мөмкин:

*Густав Флобер. Молох хөрмәтенә корбан бирү. «Саламбо» романыннан өзек (З.Фәрдиева тәрҗемәсе).*

*Джованни Бокаччо. Чиполла ага... (З.Фәрдиева тәрҗемәсе).*

*Поджо Браччолини. Этен зиратка күмгән священник турында (З.Фәрдиева тәрҗемәсе).*

*Ромэн Роллан. Брэвск кюресы. «Кола Брюньон» романыннан өзек (М.Хәмидуллин тәрҗемәсе).*

*Шарль де Костер. Клааснын үлеме. «Уленшпигель турында легенда» китабыннан өзек (Н.Әхмәтҗанова тәрҗемәсе).*

*Проспер Мериме. Варфоломей төне. «Карл IX чорының хроникасы» китабыннан өзек (Н.Әхмәтҗанова тәрҗемәсе).*

*Э.Хемингуэй. Җан коючылар (Р.Даутов тәрҗемәсе)*

*Э.Хемингуэй Карт белән диңгез (Я.Шәмсетдинов тәрҗемәсе).*

*Джек Лондон. Мартин Иден (Ф.Миңнуллин тәрҗемәсе).*

Тәрҗемә әсәрләре ярдәмендә татар укучысы көнбатыш әдәбияты, сәнгате, белем һәм мәдәният казанышлары белән

таныша, аларны үзенә үрнәк итеп алып, милләтне мәгърифәтле һәм мәдәниятле итү идеяләрен алга сөрә.

Күренә ки, татар әдәбияты үзенең үсү юлында бөтен мөмкинлекләрне дә файдаланырга тырыша, кайсы телдә язылуына карамастан, татар тәрҗемәләре фәкать бер максатка, ул да булса, әдәбиятын үстерүгә, аны яңа баскычка күтәрүгә хезмәт иткәннәр.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1**. Инглиз язучы Фил Хэлийның (Phil Healey "Stranger than fiction: urban myths") юмористик хикәясен тәрҗемә итеп карагыз. Татар әдәбиятында аңа аваздаш хикәяләр бармы? Инглиз юморы белән татар юморы аерыламы?*

*The Bigger, the Better?*

A rich woman drove her big expensive new car to the supermarket. She arrived and thought, 'There aren't many places to park the car ... where can I leave it?' Suddenly she saw a parking place between a big blue car and a motorbike but it was very small. 'It's going to be very difficult to get this big car in there, but I'll try.'

At the same time two young women in a small old car came to the supermarket.'Where can we put the car?' the driver asked her friend.

'Look, there's a good place ... near that blue car over there,' she said. It was the same parking place between the blue car and the motorbike.

'Oh, yes,' the driver said. 'I can easily get in there.'

The rich'woman started to turn her Car into the parking place. 'I hope I *can* get in there,' she thought.

Suddenly the two young women drove into the parking place in front of her. The driver opened the window, looked at the rich woman and said,'When you learn to drive that big car, then you can do that, too!'

The rich woman was very angry but she said nothing. She turned her car and drove back as far as she could.Then she drove fast at the small car and hit it hard. She broke the lights and other things on the small car. She opened her window and called to the two young women, 'When you have money, then you can do that, too!

***2.*** *Ш.Мөдәрриснең инглиз теленнән турыдан-туры тәрҗемә иткән В.Шекспирның 66 нчы сонетына анализ ясагыз. Татар әдәбиятында әлеге сонетта күтәрелгән пробемаларга кайчан һәм кемнәр мөрәҗәгать итәләр?*

Үлем көтәм, арып, җаным бизгән чакта,
Лаек хезмәт хәер эстәп йөргән чакта;
Җыен йолкыш кәеф-сафа чиккән чакта,

Җыен мөртәт тугърылыктан көлгән чакта, –
Алдакчылар яман мактау алган чакта,
Фәхишәлек кызлык күркен бозган чакта;
Камиллеккә мәсхәрәләр яуган чакта,
Чулак куллар юлга киртә корган чакта, –
Муза телен зур исемнәр кискән чакта,
Булдыксызлар осталыкны буган чакта;
Бөтен хакны нахак басып киткән чакта,
Яхшылыкны яман нәрсә куган чакта, –
Арып тәмам, җаным бизеп, үлем көтәм,
Үләр идем – дустым кала, үзем китәм...

## 8 НЧЕ ТЕМА. ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛЕШЕ

Тугандаш халыклар әдәбияты да татар укучыларына киң билгеле. Мәсәлән, үзбәк, төрек, чуваш, әзербәйҗан, казакъ, мари, уйгыр, кыргыз, каракалпак, ногай язучыларының әсәрләре тәрҗемә ителгән.

Татар әдәбиятында төрки халыкларның әдәбиятын татарчалаштыру өлкәдәсендә **Сәрвәр Әдһәмова** зур уңыш казанды дисәк ялгыш булмас. Аның хезмәте нәтиҗәсендә татар укучысы казак язучысы Мохтар Әүзовның "Абай"

романы белән танышу бәхетенә ия булды. **Лирон Хәмидуллин** исә, үзбәк язучысы Әсгать Мохтарның "Чинар" «романын яңадан эшләп чыгарды. Болар, һичшиксез, татар тәрҗемәчелеге тарихында зур казаныш буларак бәяләнергә хаклы.

80 елларда бездә әзербайҗан, казакъ, төрекмән һ.б. халыклар әдипләренең күмәк хикәя яки повесть, шигырь җыентыклары да даими рәвештә туплап басылып килгән. Мәсәлән, каракалпак халкы әдәбияты антологиясе «Арал дулкыннары», Идел буе республикалары язучыларының күмәк җыентыклары, казакъ авторлары повестьлары тупламалары «Ак дөя», «Җәйләүдә», «Дала гөлләре», союздаш һәм автономияле республикалар әдипләренең сайланма хикәяләр җыентыгы «Дуслык аланы» һ.б. бездә зур тиражлар белән нәшер ителгәннәр.

Кардәш төрки телләрдән тәрҗемә итүче осталар рәтендә **Сәрвәр Әдһәмова, Нури Арслан, Әхмәт Исхак, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәен һәм Тәүфикъ Әйди, Харрас Әюпов, Лирон Хәмидуллин, Асыя Рәхимоваларны** атарга мөмкин:

**Төрек** әдәбиятыннан тәрҗемә үрнәкләре:

***“Кил әле, таныш булыйк”*** (төрек әдәбияты җәүһәрләре) җыентыгы (Казан, 2005), Асыя Рәхимова (КФУ талибәсе) тәрҗемәләре:

**Өмәр Сәйфеттин.** Вәлинигъмәт – шәфкать иясе

**Өмәр Сәйфеттин.** Биек үкчәләр

**Тарык Бугра.** Кече Ага. (Романнан өзек)

**Тарык Бугра.** Улыбыз

**Сабахаттин Али.** Хәсән чоңгылы

**Мәхмәт Сейда.** Авылга бәхет китерүче Мәмәт

**Шәвкәт Булут.** Язмыги

**БеһзатАй.** Мирас бүлешү

**Бурһан Гүнәл.** Кышның хәле башка

**Алев Алатлы.** Ясминнәр һаман да томаннар артындамы? («Ясминнәр» романыннан өзек)

**Орхан Памук.** Өч мушкетер («Кара китап» романыннан өзек)

**Орхан Памук.** Минем исемем Кызыл (романнан өзек).

***“Беренче намаз****: төрек һәм төрки шигырьләр, хикәятләр, хикмәтләр, хикәяләр” җыентыгы (Казан, 2010), Бикә Рәхимова тәрҗемәләре:

**Юныс Әмрә** (XIII гасыр) Мөхәммәд (С.Г.В.)

**Мәүләнә Җәләлетдин Руми** (XIII гасыр) Оста белән кылый, Газраилдән качкан адәм, Падишаһ һәм аның ике колы, Кибетче һәм тутый кош, Алама гадәт, Ач ишәк.

**Ашык Өмәр** (XVII гасыр) Былбыл газап чигә

**Ашык Рәйхани** (XX гасыр) Кошма

**Атсыз** (XX гасыр) Чакыру

**Рамазан Айтан** (XX гасыр) Ашау

**Кыргыз** әдәбияты үрнәкләре:

**“Кыргыз ангемелери”** (50-60 елларда иҗат иткән язучыларның хикәяләре) җыентыгы:

**Чыңгыз Айтматов**. Солдат улы**.** Ләбибә Ихсанова тәрҗемәсе

**Шабданбай Абдыраманов**. Солдат. Яхъя Халитов тәрҗемәсе

**Мар Байҗиев**. Елмаю. Яхъя Халитов тәрҗемәсе

**Камбаралы Бобулов**, Иркенбәк. Миркасыйм Госманов тәрҗемәсе

**Мурза Гапаров**. Тургай. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе. Кара күлнең казлары. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе. Наташа Ростованың беренче балы. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе. Ак төндә туган кыз. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе.

**Касыйм Каимов**. Тау чишмәсе. Миркасыйм Госманов тәрҗемәсе

**Җунай Мәүләнов**. Кабартма. Яхъя Халитов тәрҗемәсе

**Роза Рыскелдинова**. Кызыл кашлы йөзек. Ләбибә Ихсанова тәрҗемәсе

**Шатмая Садыбакасов**. Яшенле көн. Миркасыйм Г оеманов тәрҗемәсе

**Аман Саспаев**. Сары эт. Ләбибә Ихсанова тәрҗемәсе

**Исраил Сөләйманов**. Бала. Миркасыйм Госманов тәрҗемәсе

**Биксолтан Җакиев**. Мин абыемнан олырак. Миркасыйм Госманов тәрҗемәсе

**Ашым Җакыпбеков**, Айкашка. Яхъя Халитов тәрҗемәсе

**Ходайбиргән Җапаров**, Председательнең кайбер көннәре. Миркасыйм Госманов тәрҗемәсе.

**Кубатбек Җусубалиев**, Тауга яз кичегеп килә. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе

**Киңәш Җусупов**, Аптечка. Хава Хөсә ено ва тәрҗемәсе. Иске рәис. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе. Йөрәгем минем тауларда. Хава Хөсәенова тәрҗемәсе.

**Казакъ** әдәбияты:

“Җәйләүдә” җыентыгы (Казан, 1993), Л.Хәмидуллин тәрҗемәләре:

**Ә.Әлимҗанов** Күкшел таулар илендә. Отрар хатирәсе.
**С.Моратбәков** Кыр.Магауин Кара кыз.
**У.Букиев** Ялгыз яучы

**Башкорт** әдәбияты:

Аралбай К. Ак тирмәләр иле (шигырьләр, поэмалар җыентыгы) Х.Әюпов тәрҗемәсе.

**Калмык** әдәбияты:

Ирәнҗән Хара-Дауан Чыңгыз хан (эссе). Марсель Галиев тәрҗемәсе

**Каракалпак** әдәбияты:

Арал дулкыннары (җыентык), 1981, Казан, Төзүче Л.Хәмидуллин.

**Чуваш** әдәбияты:

Юхма М. Көнгыш – үлемсезлек кошы (Казан, 1987), повесть, М.Вәлиев тәрҗемәсе.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1***. *Башкорт шагыйре Ирек Киньябулатовның “Ир сүзе” шигырен (Х.Әюпов тәрҗемәсе) анализлагыз. Татар һәм башкорт лингвомәдәниятендә ир-ат образы ничек гәүдәләнә?*

Атлавыннан танып була ирне,
Кодрәтлеме, нинди куәтле.
Карашыннан танып була ирне,
Нинди уйлы, нинди ниятле.
Кулларыннан танып була ирне,
Нинди эшләр аннан килгәнен,
Эше белән кеше булганлыгын,
Үз кадерен үзе белгәнен.
Ярасыннан танып була ирне,
Нинди утлар-сулар кичкәнен.
Ак чәченнән белеп була хәтта
Кайгы-хәсрәт күпме төшкәнен.
Ирнең кем икәнен, ни икәнен
Раслый аны хәтта берүзе:
Ирне ир иткән дә, зур иткән дә,
Иң нык таныткан да ир сүзе
Туган җиргә
Бу тормышта яшәвемнең сере,

Бөтен мәгънәсе – ярату.

Мәхәббәтнең барлык кайнарлыгын

Тик-тик туган җиргә тарату.

**2.** *Бикә Рәхимова тарафыннан тәрҗемә ителгән төрек классигы Юныс Әмрә (XIII йөз) шигырен укыгыз. Тәрҗемәдә шул чор рухы сакланганмы, моның өчен нинди ысуллар кулланылган?*

Хәят суын киптереп, җанны мәҗүси утка бирдек,
Җәүһәрләрне – рибачыга, алтынны да шуңа бирдек.
Белмим, ул сәүдәгәр кемдер, табышын да күрәлмәдем,
Чөнки табышын да җуеп, зыянны күмәлмәдек.
Мәгърифәтле затлар аңламас бу мәгънәсез сәүдәне,
Утка салдык җиһанны, җиргә – кәфенсез гәүдәне.
Көфер белән иман сыялмаслар бер үк тайгак юлга,
Сафа кылдык кяфер белән, иманны куеп сулга.
Кода-кодагыйлык кылдык ла, яман囲штә тотылдык,
Инде дуслык та бетте, бер-беребезне тоттырдык.
Безнең шушы базарыбызда сәүдәгәр булды хәйләкәр,
Заманга юлладык гаепне, аңа кунды барча әр.
Бу чикле дәвернең заманы аңламас шул Юнысны,
Чиксез дәвергә өндәдем җирем-суым, олысны.

***3.*** *Төрек классигы Мәүләнә Җәләлетдин Руми хикмәтләренең татарчага тәрҗемәләре белән танышыгыз (Б.Рәхимова тәрҗемәсе). Тәрҗемә бербөтен булып укыламы?*

ОСТА БЕЛӘН КЫЛЫЙ

Оста бер кылыйга: – Шешәне алып бир әле, – диде.

Кылый:

– Анда ике шешә бит, кайсын бирим соң? – диде.

Оста әйтте:

– Анда шешә ике түгел, кылыйлыгыңны бетер, – диде.

– Оста, минем белән шаярма, анда шешә – икәү! – диде кылый кабат.

Шуннан соң оста:

– Алайса, ул ике шешәнең берсен бәреп ват, – диде.

Өйрәнчек шешәнең берсен бәреп ваткан иде, шешәләрнең икесе дә юкка чыкты. Шешә бер данә иде, фәкать кылый өйрәнчекнең күзенә ике булып күренә иде. Ходай чыгымчы һәм кире адәмне кылый итәр, туры юлдан аерыр.

# 9 НЧЫ ТЕМА. ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ТЕЛЛӘРЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕ

Кардәш әдәбият вәкилләре әсәрләре татарча шактый басылып чыккан. Үз чиратында алар да бурычлы булып калмаган. Мәсәлән, **Казакъстанда** «Дуслык көтепханәсе» сериясендә күләмле «Татар повестери» китабы, **Үзбәкстанда** «Йиллар ва йуллар», **Каракалпакстанда** «Татар гүрриңлери» исемендә хикәя җыентыклары, **Азәрбайҗан** белән **Кыргызстанда** да шундый ук күләмле җыентыклар басылып чыкты. Әлбәттә, ул республикаларда андый күмәк җыентыклардан тыш та татар әдипләре әсәрләре тәрҗемә ителгән. Шул җәһәттән аеруча казакъ кардәшләрне аерым билгеләп үтү урынлы булыр. Сугыштан соңгы чорда Казакъстанда һәр елны диярлек икешәр-өчәр татар китабы дөнья күргән. Г.Тукай, М.Җәлил җыентыклары да даими рәвештә басыла торган. Үзбәкләр дә алардан калышмаска тырышты. Үзбәкстанда татар әдәбияты таралышына зур әһәмият бирүчеләрдән милләттәшләребез **Габдулла Уразаев** белән **Әсгать Мохтарны** аерым искә алу кирәктер.

Бүгенге көндә аеруча татар теленнән төрек теленә тәрҗемә итү шактый популярлашып бара. Мәсәлән,

Төркиядә махсус проект нигезендә 7 ел эчендә төрек әсәрләре 41 телгә тәрҗемә ителгән, 50 илдә басылып чыккан һәм алар әлегә барлыгы 748 китап. 2005-2012 еллар аралыгында Төркиядә дөнья күргән татар әсәрләре шактый:

1. “VASIYET” исемле җыентык. «Замбак» нәшриятында 2005, 2006 һәм 2012 елларда өч басмасы дөнья күрә. Анда кергән әсәрләр профессор Хатыйп Миңнегулов тәкъдиме белән сайланып, китап аның кереш сүзе белән чыга. Тәрҗемәчеләре – **Фатих Кутлу, Хамза Әрсой, Надир Тамәр Аслан**. Җыентыкка кергән әсәрләр: Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык»; Шәриф Камал «Буранда», «Уяну»; Фатих Әмирхан «Бер харәбәдә», «Сәмигулла абзый»; Галимҗан Ибраһимов «Табигать балалары»; Мирсәй Әмир «Мөстәкыйм карт йокысы»; Фатих Хөсни «Сөйләнмәгән хикәя»; Миргазиян Юныс «Безнең өй өянкеләр астында иде».

2. Разил Вәлиевнең «MAVI HÜZÜN» («ЗӘҢГӘР САГЫШ») җыентыгы «Da» нәшриятында 2007 елда дөнья күрә. Тәрҗемә итүчеләр – **Фатих Кутлу, Харун Тосун.** Бу китаптагы «Дуслык учагы» дигән шигырьгә композитор Кәмал Кутлу төрекчә көй яза. Шулай итеп, әлеге җыр сүзләре төрекчәгә тәрҗемә ителеп, аңа төрекчә көй язылган беренче татар җыры булып тарихка кереп кала.

3. Аяз Гыйләҗевнең «BIR AVUÇ TOPRAK» («ӨЧ АРШЫН ҖИР») повесте **Фатих Кутлу** тәрҗемәсендә һәм профессор Хатыйп Миңнегуловның кереш сүзе белән «Сүтун»нәшриятында 2008 (2 басма), 2011 елларда басылып чыкты. Аяз Гыйләҗевнең Фатих Кутлуга васыяте буенча тәрҗемә ителә. Әсәрнең чыгуы мәрхүмнең 80 еллыгына туры килә һәм ул 2012 елда Ауразия Язучылар берлегенең «Төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы тәрҗемә» номинациясендә җиңү яулый. Повесть турында төрек матбугатында дүрт тәнкыйть мәкаләсе дөнья күрә.

4. «HECE ÖYKÜ» журналының «Хәзерге татар хикәясе» дигән 54 нче номерлы махсус «декабрь-гыйнвар» саны. **Фатих Кутлу** тәрҗемә иткән хикәяләр Әлфәт Закирҗановның кереш сүзе белән чыга. Анда ун автордан берәр хикәя урын ала, алар түбәндәгеләр: Айгөл Әхмәтгалиева «Җиде ят», Асия Юныс «Бәби мунчасы»; Аяз Гыйләҗев «Күлмәк»; Галимҗан Гыйльманов «Күңел күзең күрәме?»; Дания Гайнетдинова «Бәхет яшьләре»; Зөлфәт Хәким «Чын ярату»; Марсель Галиев «Балачак әсирлегендә»; Рабит Батулла «Хәерче Габәш»; Рәмзия Габделхакова «Китүчеләр»; Ркаил Зәйдулла «Ак эт».

5. Аяз Гыйләҗевнең «CUMA GÜNÜ, AKŞAM...» («Җомга көн, кич белән...») әсәре **Фатих Кутлу**

тәрҗемәсендә һәм Миләүшә Хәбетдинова кереш сүзе белән «Бәнгү» нәшриятында 2013 елда дөнья күрә. Әлеге хезмәт алдан ук планлаштырып куйган төсле Аяз аганың сиксән биш еллыгына туры килә (тәрҗемә дүрт ел бара).

6. «Тавышсыз курай» (хәзерге татар әдәбиятыннан хикәяләр) җыентыгы «Бәнгү» нәшриятында 2013 елда басылып чыга. Әлеге китапта «Несе Öykü» журналының 54нче номерына керә, өстә телгә алынган 10 хикәядән тыш Рабит Батулланың «Тавышсыз курай» әкияте һәм Әсгать Салахның «Соңгы вальс» повесте урын ала.

**Гамәли дәрес өчен сораулар һәм биремнәр.**

***1**. Эльмир Гобаевның “Тәрҗемә мәсьәләләре” мәкаләсен укып фикер алышыгыз.*

***2.** Чулпан Зариф-Четин тарафыннан* Р.Гаташның төрекчәгә тәрҗемә ителгән робагыйларын укыгыз, анализлагыз.

Rubai, sen eski sözün bostani!
Ol bugün yazdiklanmm gülhani!
Süyümbike ilhan, Nogay kavali
Hüznüdür bu. Bizde onun ilhami...
***
Ayirma halkim gammdan, ya Rabbim!
Doĝar doĝmaz canimi ile kattin.

Muhabbet tohumu attin sen ona,
İhlâs his ve paк yaş için yarattin!

*Bugüniimüz*

İlahi saz ! Sen, hüzünden ibaret.
Tanri mi çalar seni? Bu nasil dert?
...Sizi saz da uyandirmaz, taş canlar!
Bөyleyiz artik biz, ah Tukay, Derdmend!

## ИМТИХАН ӨЧЕН ЯКЫНЧА СОРАУЛЫК

1. Әдәбиятның үсешендә тәрҗемәнең роле.
2. Татар теленнән рус теленә әдәби тәрҗемә итү эшчәнлеге.
3. Рус әдәбияты үрнәкләре татар телендә.
4. Лев Толстой – татар телендә.
5. Татар телендә Көнбатыш әдәбияты.
6. Тугандаш халыклар әдәбияты үрнәкләренең татар теленә тәрҗемә ителеше.
7. Татар әдәбияты әсәрләре һәм аларның төрки халыклар телләренә тәрҗемәсе.
8. Инглиз әдәбиятыннан татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләр.
9. Төрек теленә тәрҗемә ителгән татар әдәбияты әсәрләре.

10. Көнбатыш әдәбиятыннан тәрҗемә ителгән әсәрләрнең татар әдәбиятына алып килгән яңа темалары, жанрлары.

11. Тәрҗемәләрдә чор рухының чагылышы.

12. Рус әдәбияты үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итүче актив тәрҗемәчеләр.

13. Бүгенге көндә әдәби тәрҗемә торышы

14. Татар әдәбияты үсешендә тәрҗемәнең роле.

15. 19 йөз ахыры – 20 йөз башында тәрҗемә эшчәнлеге.

16. Совет чоры вакытында тәрҗемәнең торышы.

17. Г.Тукайның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге.

18. Тәрҗемәче Фатих Котлуның татар әдәбияты үрнәкләрен төрек дөньясына танытудагы роле.

19. К.Миңлебаев, А.Рәхимова, Б.Рәхимова, Л.Хәмидуллин һ.б. тәрҗемәчеләрнең эшчәнлеге.

20. “Каләмнәр дуслыгы” сериясендә чыккан китапларга күзәтү.

## РЕФЕРАТ ТЕМАЛАРЫ

Татар телендә шигырь тәрҗемәсе (Гомәр Хәйям робагыйлары буенча)

Татар телендә шигырь тәрҗемәсе (А.С.Пушкин тәрҗемәләре буенча)

Татар телендә шигырь тәрҗемәсе (У.Шекспир сонетлары буенча)

Татар телендә драма тәрҗемәсе (У.Шекспир тәрҗемәләре буенча)

Татар телендә проза тәрҗемәсе (Л.Н.Толстой тәрҗемәләре буенча).

Татар телендә проза тәрҗемәсе.

Г.Тукайның башка телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләрендә милли колоритның бирелеше.

Тугандаш башкорт халык әдәбияты татар тәрҗемәләрендә.

Фатих Котлуның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге.

Татар халкының танылган тәрҗемәчеләре (19 йөз ахыры – 20 йөз башы).

Татар халкының танылган тәрҗемәчеләре (20 йөз ахыры – 21 йөз башы).

Татар әдәбияты һәм тәрҗемә.

Бүгенге көндә әдәби тәрҗемә торышы.

Тәрҗемә эшен оештыру

Поэзия әсәрләрен тәрҗемә итүчеләргә күзәтү

Проза әсәрләрен тәрҗемә итүчеләргә күзәтү

## “ЧАГЫШТЫРМА ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ СИСТЕМАСЫНДА ТӘРҖЕМӘ” КУРСЫ БУЕНЧА ТЕСТ

**1. Әдәби тәрҗемә́** ул –

А) чыганак телдән тәрҗемә теленә җиткерү өчен алынган билгеле бер мәгълүматны үз эченә алган интеллектуаль эшчәнлек.

Б) бер телдә язылган әсәрне, аның стилистик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап калырга тырышып, икенче телгә күчерү.

В) бер телдә әйтелгән, язылган фикерне, сүзне, әсәрләрне икенче тел чаралары белән коммуникатив яктан тәңгәл килгән текст рәвешендә бирү.

**2.** Рус язучыларын өйрәнү, әсәрләрен тәрҗемә итү, ияреп язу

А) XIX гасырда колач ала

Б) 1905 елдан соң аеруча колач ала

В) 1960 нчы еллардан соң гына колач ала.

**3**. Татар теленә беренче мәртәбә кайчан һәм кайсы халык әдәбияты әсәре тәрҗемә ителгән:

А) фарсы

Б) гарәп

В) төгәл билгеләве кыен

**4**. Г.Бәшировның әсәрләре рус теленә

А) тәрҗемә ителгән

Б) тәрҗемә ителмәгән

**5**. А.Гыйләҗевнең әсәрләре төрекчәгә

А) тәрҗемә ителгән

Б) тәрҗемә ителмәгән

**6.** Д.Дефоның "Робинзон Крузо" әсәре татарчага

А) бер генә тәрҗемәче тарафыннан тәрҗемә ителә

Б) бер генә тәрҗемәче тарафыннан тәрҗемә ителеп, берничә тапкыр нәшер ителә

В) берничә тәрҗемәче тарафыннан тәрҗемә ителә.

**7.** С.Маршак шигырьләренең татарча тәрҗемәләре

А) кызганычка каршы, юк

Б) бар.

**8**. XX йөз башы тәрҗемә әсәрләрнең 72% -ы

А) поэзия әсәрләре

Б) проза әсәрләре

В) драма әсәрләре

**9.** Ркаил Зәйдулланың төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре

А) бар

Б) кызганычка каршы, юк

**10**. Мольерның

А) татар теленә тәрҗемәләре бар

Б) рус теленә генә тәрҗемәләре бар

В) татар теленә тәрҗемәләре юк

**11**. Көнбатыш әдәбияты татар халкына

А) бары тик рус теле аша

Б) төрек теле аша

В) берничә юл (рус, төрек телләре аша, оригиналдан) белән керә

**12.** Тәрҗемә ителгән көнбатыш әдәбияты әсәрләре арасында басма саны ягыннан беренчелекне

А) француз язучысы Жюль Вернның "Капитан Грант балалары әсәре алып тора

Б) инглиз язучысы Д.Дефоның “Робинзон Крузо” әсәре алып тора

В) немец язучысы Эрих Мария Ремаркның әсәрләре алып тора

**13**. Каракалпак әдәбияты үрнәкләре татар теленә

А) тәрҗемә ителгән

Б) әлегә тәрҗемә ителмәгән

**14.** 40-50 елларда татар телендә чыккан әсәрләренең күплеге буенча беренче урында

А) А.С.Пушкин тора

Б) А.М. Горький тора

В) Л.Н.Толстой тора.

**15**. Бер үк әсәр берничә тәрҗемәче тарафыннан эшләнеп, төрле вариантларда басылу

А) фактлары бар

Б) фактлары әлегә юк.

## КУРСНЫ ӨЙРӘНҮНЕ ОЕШТЫРУГА КАРАТА МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

***Укытучы өчен методик күрсәтмәләр***. “Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсы 032700.62 “Гамәли филология: мәдәниятара багланышлар һәм тәрҗемә” белгечлеге буенча өйрәнелә торган лингвистик фәннәрнең иң соңгыларыннан буларак, студентларның татар, рус телләреннән, шулай ук әдәбият белеменнән теоретик һәм гамәли дәресләрдә тупланган белем-күнекмәләренә таянып укытуны күздә тота

Әлеге курс төрле халык әдәбияты әсәрләренең татарча чыккан тәрҗемәләре әдәбиятыбызга алып килгән яңа темалары, идеяләре, аны жанр ягыннан баетуы, әдәби тәрҗемәләрнең шул чор рухын чагылдыруы белән таныштыруны, нинди жанрларга, темаларга ихтыяҗ зур булганлыгы, актив тәрҗемәчеләр, тәрҗемә ителгән әсәрләрнең телен өйрәнүне максат итеп куя.

Программада тәрҗемә теориясе нигезләре саклану белән беррәттән яңа хезмәтдәргә дә игътибар итү күз алдында тотыла. Тәрҗемә белемендә тулаем расланмаган, яки гомум кабул ителмәгән мәсьәләләргә карата үз фикерен укытучы альтернатив рәвештә аудиториягә җиткерә.

“Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсының төп теоретик материалы лекцияләрдә бирелә: тәрҗемә һәм әдәбият белеме арасындагы бәйләнеш ачыклана.

Алынган мәгълүматларны ныгыту, студентларның лингвистик фикерләү сәләтен һәм тел фактларын анализлау осталыкларын үстерү максатында, семинар дәресләр үткәрелә, татар теленә тәрҗемә ителгән төрле халык әдәбияты әсәрләре һәм татар әдәбияты казанышларының башка телләргә тәрҗемә үрнәкләре анализлана.

Дәресләрне алып баруда такта, таблицалар, “Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә” курсы өчен төзелгән үрнәк программадан, сүзлекләрдән, курста карала торган темаларга кагылышлы монографияләрдән файдаланыла.

Курсны өйрәнү барышында студентларның язма һәм сөйләмә рәвештә биремнәр үтәве, докладлар белән чыгышлар ясавы да күздә тотыла. Мөстәкыйль эш буларак,

студентларга тәкъдим ителгән темаларга реферат яздырырга да мөмкин. Материалны үзләштерү дәрәҗәсен тикшерүнең шактый нәтиҗәле алымы буларак тест үткәрү уңышлы.

Студентларның "Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә" курсын үзләштерү дәрәҗәсе имтихан ярдәмендә ачыклана. Семестр дәвамында семинар һәм гамәли дәресләрдә җаваплар, гомумән, дәрескә йөреш, тест нәтиҗәләре әлеге имтиханда билге куйганда исәпкә алынырга тиеш.

***Студентлар өчен методик күрсәтмәләр***. "Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә" курсы 8 нче семестрда 24 сәгать лекция, 16 сәгать гамәли дәрес, мөстәкыйль эшләр өчен 32 сәгать күләмендә планлаштырылган. Үзләштерелгән белем имтихан ярдәмендә бәяләнә.

Мөстәкыйль сәгатьләрдә студентлар:

- темага кагылышлы теоретик материалны үзләштерә, ныгыта;
- тәкъдим ителгән төп һәм өстәмә әдәбиятны укый;
- тәкъдим ителгән темаларга материал әзерләп, гамәли дәресләрдә чыгышлар ясый;

- тәрҗемәләрдәге фразеологизмнарга, реалияләргә, милли колоритны белдерүче чараларга анализ ясый;
- рефератлар яза һәм аны яклый.

## ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ (ГЛОССАРИЙ)

**Әдәби тәрҗемә** – бер телдә язылган әсәрне, аның стилистик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап калырга тырышып, икенче телгә күчерү**.**

**Әдәби тәрҗемәнең бурычы** белем, мәгълүмат бирү, матурлык хисе тәрбияләү.

**Әдәби тәрҗемәнең максаты** - әдәби казанышны башка халыкларга җиткерү, әдәби бәйләнешләрне ныгыту.

**Әдәби тәрҗемәнең төп предметы –** әдәби әсәр.

**Әдәби тәрҗемәнең төп функциясе** укучыларга әдәби-эстетик тәэсир итү булган текстларны тәрҗемә итү.

**Букваль шигъри тәрҗемә –** оригиналга ияреп тәрҗемә итү, сәнгатьчә эшләнеше, шигъри калып югалырга мөмкин. Бу тәрҗемә икенче төрле «подстрочный перевод» дип тә атала.

**Диахроник тәрҗемә** – узган гасыр телендә язылган тарихи текстның хәзерге телгә тәрҗемәсе.

**Семантик-стилистик адекват тәрҗемә** – тәрҗемә ителә торган телнең функциональ-стилистик нормаларына

туры килгән, семантик яктан тулы, төгәл, стилистик яктан эквивалент булган тәрҗемә.

**Стильгә салынган шигъри тәрҗемә** – тәрҗемәнең ирекле төре, гомуми мәгънә, эчтәлек саклана, ләкин төзелеше, формасы буенча оргиналыннан шактый ерак. Бу тәрҗемә төре шактый сирәк кулланыла.

**Транскрипция** – чыганактагы лексик берәмлекнең аваз формасын тәрҗемә ителә торган тел хәрефләре ярдәмендә бирү юлы белән тәрҗемә итү ысулы.

**Транслитерация** – чыганактагы лексик берәмлекнең график формасын тәрҗемә ителә торган тел хәрефләре ярдәмендә бирү юлы белән тәрҗемә итү ысулы.

**Тәрҗемә** – бер телдә әйтелгән, язылган фикерне, сүзне, әсәрләрне икенче тел чаралары белән коммуникатив яктан тәңгәл килгән текст рәвешендә бирү.

**Функциональ шигъри тәрҗемә** – тәңгәллекләр сайлауга нигезләнә, текст оригиналга яраклаштырып эшләнә. Бу төр тәрҗемә киң таралган.

**Формаль шигъри тәрҗемә** – кирәкле рифма һәм әйләнмәләр сайлап алып, сүзгә сүз тәрҗемә итү. Бу төр тәрҗемә иң идеаль санала.

**Шигъри әдәби тәрҗемә** – оргиналга ияреп тәрҗемә итү, шул ук вакытта тәрҗемә теле үзенчәлекләренә

яраклаштырып эшләнә. Төп максат булып шигырьнең стилен мөмкин кадәр саклау.

**Эквивалентлы тәрҗемә** – чыганак эчтәлеген эквивалентлыкның билгеле бер дәрәҗәсендә чагылдыра торган тәрҗемә**.**

**Эквивалентсыз лексика** – чыганак телнең тәрҗемә ителә торган телдә даими (сүзлек) тәңгәллекләре булмаган лексик берәмлекләре.

## ЧЫГАНАКЛАР


Абай. Шигырьләр һәм поэмалар / Ибраһим Конанбаев; кереш сүз авт. С. Хәким; төз. Л. Хәмидуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1981. – 256 б.

Абай. Шигырьләр һәм поэмалар / Ибраһим Конанбаев; кереш сүз авт. С. Хәким; төз. Л. Хәмидуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1981. – 256 б. – Казакъ язучысы.

Айтматов Ч. Бер көн – бер гомер: роман / Чыңгыз Айтматов; Р. Шириязданов тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1990. – 286 б. – Кыргыз язучысы.

Амадо Ж. Габриэланың гыйшкы: роман / Жорже Амадо; К. Миңлебаев тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1999. – 463 б. – Бразилия язучысы.

Анак Ш. Тыйнак табын: шигырьләр / Шамил Анак. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. – 256 б. – Башк. шагыйре.

Арал дулкыннары: Каракалп. язучыларының әсәрләре / төз., кереш сүз һ. биогр. белешмәләрне әзерләүче Л. Хәмидуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1981. – 544 б.

Аралбай К. Ак тирмәләр иле: шигырьләр, поэмалар / Кадим Аралбай; [башк. Х. Әюп тәрҗ.]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1996. – 364 б

Астафьев В.П. Талау: повестьлар / Виктор Астафьев; русчадан Т. Нурмөхәммәтов тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1983. – 352 б.

Бәхетлеме икән ул: эстон хикәяләре / төз. Т. Әйди. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1990. – 187 б.

Беренче намаз: төрек һәм һәм төрки шигырьләр, хикәятләр, хикмәтләр, хикәяләр. – Казан: Ихлас, 2010. – 143 б.

Биккол Ш. Сандугач кунды талларга: шигырьләр, җырлар, поэмалар / Шәриф Биккол; Г. Хөсәеновның кереш сүзе б-н; Х. Әюп тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1995. – 527 б. – Башк. шагыйре.

Гарсиа М. Ялгызлык: роман / Габриэль Гарсиа Маркес; К. Миңлебаев тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1987. – 368 б. – Колумбия язучысы.

Гүнтекин Р.Н. Чалы кошы: роман / Ришат Нури Гүнтекин; [соңгы сүз авт. һ. тәрҗ. Т. Нурмөхәммәтов]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 384 б. – Төрек язучысы.

Дала гөлләре: казакъ язучыларының повестьлары / төз. Ә. Сараев; рәссамы Д. Җәләлетдинов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1991. – 434 б.

Думбадзе Н.В. Мәңгелек канун: роман / Нодар Думбадзе; русчадан Н. Вәлитова тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1986. – 231 б. – Грузин язучысы.

Җәйләүдә: казакъ повестьлары / Л. Хәмидуллин тәрҗ. һ. кереш сүзе. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1993. – 480 б.

Кәрим М. Гомер мизгелләре / Мостай Кәрим; [башк. Н. Вәлитова тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1996. – 175 б.

Киньябулатов И. Урал курае. – Казан: 2008. – 107 б. – Башкорт шагыйре.

Көгелтинев Д.Н. Иркенлек : шигырьләр, поэма / Давыт Көгелтинев; тәрҗ. Г. Рәхим. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1983. – 127 б. – Калмык шагыйре.

Куприн А. И. Повестьлар / Александр Куприн; Р. Даутов тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1988. – 496 б.

Несин А. Эт койрыгы: юморист. хикәяләр / Азиз Несин; Н. Кәримова тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1991– 176 б. – Төрек язучысы.

Пушкин А.С. Хәтерлим мин гүзәл бер мизгелне...: шигырьләр / Александр Пушкин; татар шагыйрьләре тәрҗ.; [төз. Х. Фәйзрахманова]. – Казан : Мәгариф, 1999. – 141 б.

Рид Томас Майн. Башсыз җайдак: роман / Майн Рид; [русчадан Я. Халитов тәрҗ.]. – 2 басма. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1989. – 496 б. – Инглиз язучысы.

Толстой Л.Н. Егет чак: Повесть / К.Миңлебаев тәрҗ. – Казан: Таткнигоиздат. 1957. – 188 б.

Хәйям Г. Робагыйлар / Гомәр Хәйям; [кереш сүз авт. һ. тәрҗ. Н. Арсланов]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1986. – 143 б. – Фарсы-таҗик шагыйре.

Юхма М. Көнгыш – үлемсезлек кошы : М. Вахитов тур. повесть / Михаил Юхма; русчадан М. Вәлиев тәрҗ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1987. – 287 б. – Чуваш язучысы.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

*а) төп әдәбият*

Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингвист. фак. вузов / И.С.Алексеева. – М.: Академия; СПб.: Филол. фак. СпбГУ, 2004. – 352 с.

Гарбовский Н.К. Теория перевода: учебник. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 2007. – 164 с.

Комиссаров В.Н. Современное переводоведение: Учеб. пособие / В.Н. Комиссаров. – М.: ЭТС, 2004. – 420 с.

Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.

Нурмөхәммәтова Р.С. Тәрҗемә белеменең теоретик нигезләре. Укыту-методик ярдәмлек. – Казан: Вестфалика, 2010. – 164 б.

Топер П.М. Перевод в системе сравнительного литературоведения. – М.: Наследие, 2000. – 254 с.

Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

*б) өстәмә әдәбият*

Бархударов Л.С. Язык и перевод (Вопросы общей и частной теории перевода). Москва, 1975. – 239 с. Ресурс доступен также по следующему адресу: http://www.classes.ru/125.Barhudarov-yazik-i-perevod

Брандес М.П. Предпереводческий анализ текста: учебное пособие / М.П.Брандес, В.И.Провоторов. – М.: КДУ, 2006. – 240 с.

Виноградов В.С. Введение в переводоведение: Общие и лексические вопросы / В.С.Виноградов. – М.: ИОСО РАО, 2001. – 223 с.

Гобәев Э. Тәрҗемә мәсьәләләре // Мәгариф. – Казан. – № 12. – Б. 24-25.

Зәкиев М.З. Классик әсәрнең тәрҗемәсе // Совет әдәбияты. – 1952. – №2. – Б.119

Ибраһимов Г. Тәрҗемә вә аның шартлары / Г.Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. – Казань: Таткнигоиздат, 1960. – Б. 49-52.

Кәримуллин Ә. Л.Н.Толстой әсәрләре татар телендә // Совет әдәбияты. – 1960. – №11. – 149-150 б.

Кәримуллин Ә.СССР һәм чит ил халыклары әдәбияты, фольклоры һәм сәнгате. – Казан: Казан. универ. нәшр., 1963.

Курбатов Х. Татар телендә шигырь тәрҗемәсе (А.С.Пушкин тәрҗемәләре буенча) // Совет әдәбияты. – 1955. – № 9. – 96 б.

Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре / Х.Р. Курбатов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1956. – 176 б.

Курбатов Х. Шекспир сонетлары татар телендә // Совет әдәбияты. – 1957. № 6- Б. 117-119.

Миңлебаев К. Камиллеккә омтылу // Казан утлары. – 1977. – № 9. – Б. 175-180. Мөгътәсимова Г.Р. Л.Н.Толстойның "Анна Каренина" романындагы этнографик реалияләрне тәрҗемә итү үзенчәлекләре // Жизнь, посвященная тюркологии. – Казань: ТГГПУ, 2011. – С.339-342.

Миңлебаев К. Тәрҗемә – сәнгать ул! // Казан утлары. – 2005. – № 9. – Б. 142-143.

Мөгътәсимова Г.Р. Этномәдәни берәмлекләрне рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре // Академик Э.Р.Тенишев и тюркский мир. – Казань: КФУ, 2012. – С.133-136.

Нәбиуллина Г.Ә., Шангәрәева Г.У.Шекспир әсәрләренең татар теленә тәрҗемәләрендә реалийларның бирелеше. // Фәнни язмалар. 2008. Фәнни мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Ихлас, 2010. – 245-49 б.

Сафиуллина Ф.С. Язучының тел осталыгы һәм тәрҗемә / Ф.С.Сафиуллина // Казан утлары. – 1974. – №9. – С. 186-188.

Фәйзуллин С. Ике тел хәзинәсе / С.Фәйзуллин. – Казан: Тат кит. нәшр., 1964. – 108 б.

Юсупов Р.А. Тәрҗемә мәсьәләләре / Р.А.Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. – 126 б.

Юсупов Р. Тәрҗемә турында сөйләшәбез // Казан утлары. – Казан. –1986. – №5. – Б. 178-179.

Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы / Р.А.Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2008. – 240 б.

*в) интернет ресурслар*

http://www.belem.ru

http://www.elibrus.1gb.ru

http://www.nlr.ru

http://www.wikipedia.ru

http://www.slovari.ru

http://www.suzlek.ru

http://nsportal.ru/shkola/rodnoi-yazyk-i-literatura/library/tukaynyn-trzhem-eshenmonsbte

http://russian-tatar.ru

http://tatpoisk.net/dict/rus2tat/

http://kitap.net.ru

http://www.ruenglish.com/html/KT/Ezine/46.htm

http://www.helpstudent.ru/catalog/index.php?subject=188&page=2

**Габдрахманова Фануза Хайдаровна**

Печатается по решению
кафедры общего и тюркского языкознания
(протокол № 8 от 9 марта 2016 г.)

Учебно-методической комиссии Института филологии и
межкультурной коммуникации
им. Льва Толстого КФУ
(протокол № 8 от 22 марта 2016 г.)

**Перевод в системе сравнительного литературоведения.**
Учебное пособие для студентов высших учебных заведений
(на татарском языке)